# ЗӘКИ ШӘКЕРТНЕҢ МӘДРӘСӘДӘН КУЫЛУЫ

Ачылмасмы татарның ике күзе?
Җәһаләттән[1] һәлак була милләт үзе.
Моннан соң күренмәсме икән безгә
Мәгъшукымыз[2] мәгарифнең якты йөзе?

Октябрьнең соңгы көннәре якынлады. Җәйнең матур кояшлы көннәре бетеп, бөтен дөньяны болыт вә караңгылык каплады. Аяк берлән басарга кызганырлык яшел хәтфә кеби үләннәр бетә башлады. Җилбер-җилбер селкенешеп утырган агач яфраклары саргаеша вә коела башлады. Адәмнең әллә нинди кайгыларыны да тарата торган сандугач вә тургай тавышлары бетте. Дөньяның кызыгы китте. Һәр көн кар вә ягъмурлар явып, җирне былчыратып, бар гомерләрене урамда уйнап үткәргән балаларга уйнарга җайсызлый башлады.

— Урамга чыксалар, батып керәләр, чыкмасалар, өйне тыгызлап, тавышланып яталар. Бу каһәр төшкәннәрне мәдрәсәгә илтеп ташларга кирәк: икмәк кимереп ятсыннар шунда! — дигән кеби сүзләр татар агызыннан ишетелгәли башлады.

Мартта мәдрәсәдән кайткан татар шәкертләре дә:

— Инде йорттагы эшне бетердек, игенне дә җыйдык, печәнне дә китердек, азбар[3] да ясадык, мәдрәсәгә барырга кирәк! — дип сөйләнә башладылар.

Димәк, татар шәкертләренең мәдрәсәгә җыелу, мәдрәсәләрнең дә ачылу заманнары җитте. Кытрый хәзрәт тә: «Балам, шәкерт күп җыелганча, яхшырак урын алып калсын!» — дип, Зәки мәхдүмне татарның бик шөһрәтле мөдәррисләреннән Сәли хәзрәтнең[1а+] мәдрәсәсенә алып китте. Сәли хәзрәт Кышкар[1+] пишкадәмнәреннән[4] яшь вә бик мактаулысы вә бер шәһәрнең беренче мәхәлләсенең һәм ахуны, һәм мөдәррисе иде.

Безнең Зәки мәхдүм моңарча анасыннан һич аерылмаган, рәхәт вә йомшак тәрбиядә генә үскән вә шәһәрне бер дә күрмәгән иде. Шулай булса да, шәһәргә барган адәмнәрдән ишетеп, шәһәрдәге адәмнәр бик чиста вә яхшы киемнәрдән йөриләр, андагы йортлар бик өлкән вә матур була, имеш, дип хыялына урнаштырган иде.

Атасы: «Әйдә, угылым «...» шәһәренең Сәли хәзрәт мәдрәсәсенә илтим!» — дип алып киткәч, юлда барганда, үзенең барып торачак мәдрәсәсене әллә нинди өлкән вә яхшы өй булыр, мәдрәсәдәге шәкерт вә

---

[1] *Җәһаләттән* — наданлыктан.
[2] *Мәгъшукымыз* — яраткан нәрсәбез.
[3] *Азбар* – абзар.
[4] *Пишкадәмнәреннән* — алдынгы шәкерт яки иске мәдрәсәнең тулы уку курсын тәмамлаган хөрмәтле кешеләреннән.

мөгаллимнәр дә өстләренә карарга оялырлык дәрәҗәдә мәһабәтле вә ару киемле булыр, дип уйлап бара иде. Вә шул хыяллар илә шәһәргә барып, аңдагы өлкән өйләрне вә адәмнәрнең бик яхшы киемнәрене күргәч, мәдрәсә вә шәкертләр хакында улан хыялы бигрәк тә ныкланды.

Урамда ат берлән үткәндә өлкән вә матур йорт күренсә: «Бу йорт без барачак мәдрәсә түгелме?» — дип атасыннан сораша бара һәм матур өй күренгән саен: «Бу — мәдрәсәдер, шунда туктар әле!» — дип хыялланып бара иде. Озак та үтмәде, арба туктады. Зәки дә, хыялыннан бушанып: «Ни бар икән?» — дип караса, бер өй алдына туктаган идекләрене күрде. Бу өй башка өйләргә караганда карсак, буялмаган, шкатурлары кубып беткән, стенасына күмер вә акбур берлән әллә ниләр язып чобарлап бетерелгән; тәрәзәләре бик кара, каюсы ватылган, каюсыннан иске сөлгеләр салынып тора; капкасы бик начар гына вә капка төбендә һәртөрле чүпләр өелеп ята. Кыскасы, шәһәрнең башка өйләренә караганда бер ташландык өй кеби күренмәктә иде. Зәки мәхдүм, атасыннан бу өйнең мәдрәсә икәнен ишеткәч, үзенең әүвәлге хыялында ялгышкан икәнен белеп, хәзердән бер өмидсезлеккә төште. Йортның эченә кереп, атны тугардылар да, ашарга салып, бәйләп куйдылар.

Кытрый хәзрәт тә, мәхдүмне алып, мәдрәсәнең эченә кереп китте. Зәки мәхдүм кергән өйнең мәнзарасы[1] менә шул рәвештә иде: ишек төбендә һәртөрле чүпләр вә нәҗес[2] нәрсәләр өелгән, бер сулы таз; ул тазның тирәсендә төкерү вә какырудан хасил булган шакшы күл һәм аяк киемнәре вә һәртөрле комганнар бар. Өйнең түшәме, стенасы вә идәне бик кара, тузанлы, чүпле; тәрәзә төпләре сулы, черегән вә бик каралган; өйнең берничә җирендә кечкенә-кечкенә тишек киезләр вә пычак берлән әллә ниләр язылган ямьсез өстәлләр бар; вә өстәл астында икмәк, чынаяк, чәйнек, күлмәк-ыштан, тагын әллә ниләр бар; өстәл янында кап-кара тышлы мендәрләр вә каешланып беткән киемнәр, вә һәр махсус киез өстендә ике-өч кешеләр бар. Бу кешеләрнең бәгъзесе[3] намаз укый, бәгъзесе ашый-эчә, бәгъзесе йоклый, бәгъзеләре язу яза, бәгъзеләре пыялага эре-эре итеп шәмаил яза, бәгъзесе Коръәннән күчереп тәрилкәгә сары нәрсә берлән язып утыра. Бер почмакта берничә сукыр коръән укый; вә икенче почмакта аксак-туксак адәмнәр читек тегеп утыралар.

Хасил[4], өйдә ничә кеше улса – һәммәсе дә башка-башка эшләр илә мәшгуль иде. Безнең Зәки мәхдүмнең шәһәр йортлары вә адәмнәре

---

[1]*Мәнзарасы* — күренеше.
[2]*Нәҗес* — шакшы.
[3]*Бәгъзесе* — кайбере.
[4]*Хасил* — кыскасы.

хакындагы хөсне занына[1] бик хилаф[2] улдыгыннан, бу күренешне бик гаҗәпләнеп, тәмам диккать илә карап йөри; вә атасы Кытрый хәзрәт тә өйдәге һәммә адәмнәр илә күрешеп сәламләшә иде. Соңыннан, ялгызы гына бер бүлмәдә тора торган бер карт янына кереп, бик озак сөйләшеп утырып: «Тагын күрешермез әле, саг-сәламәт бул!» — дип, мәдрәсәдән чыгып киттеләр.

Мәдрәсәдән чыккач, Зәки, анда күргән нәрсәләреннән куркып китеп, атасына бу куркыныч нәрсәләр хакында сөаль бирүне лязем күрде:

— Әти! Озак сөйләшеп утырган карт кем ул? Умарта карарга бер карт ялладым дигән идең, әллә шул бабаймы? — дип сорады. Кытрый хәзрәт: «Куй, ахмак, ул карт адәм — бу мәдрәсәнең иң галим хәлфәсе; син әнә шуңардан укырсың!» — дип җавап биргәч, тәннәре эсселе-суыклы булып, моңарча анасының йомшак тәрбиясендә генә торган бала: «Мин ничек монда торырмын!» — дип, бик ямансуланды, уфтанды, кайгырды. Тагын да шул өйдә булган кабахәтләрне атасыннан бик җентекләп сораша башлады:

— Әти, нигә ул мәдрәсәне себермиләр? Нигә чүпләрене түкмиләр? Нигә бу кадәрле пычрак тоталар? Адәм тын да ала алмаслык сасы тоталар? Нигә аяк астында төрле киемнәр вә кара күлмәкләр ята? Әти, нигә бу мәдрәсәне башка өйләр кеби яхшы вә матур идеп салмаганнар? Нигә ул мәдрәсәдәге адәмнәрнең өсләре вә башлары кап-кара, киемнәре начар һәм җуылмаган? Бу — мәдрәсә булгач, ничөн андагы адәмнәр берсе дә укымый?

Хасил, ни күрсә, һәммәсе дә ник алай, ник болай түгел, — дип сораша; никадәрле сорашса да, атасыннан: «Юк, балам, «дөнья — мөэминнең зинданы», дигән; алар чын мөэминнәр, дөньялары теләсә былчырак булып-нитеп үтсен, анда кайгылары юк!» — җавабыннан башка сүз ишетми иде.

Мәдрәсәдән чыккан соң, бу мәдрәсәнең мөдәррисе улан Сәли хәзрәткә киттеләр. Барып җиттеләр Сәли хәзрәтнең өенә.

— Чалдырр!

— Кем бар?

— Кытрый мулла!

— Әйдә, рәхим идеңез, хуш килдеңез, рәхим идеңез!

Өйгә керделәр. «Әссәлямегаләйкем!» — «Вәгаләйкемәссәлям!» «Аманмы сез? Сәламәтме сезләр?»не тәкрар иттеләр[3] һәм сөйләшә башладылар. Сәли берлән Кытрый икесе бер мәдрәсәнең шәкерте булдыгыннан, гәпләре бик килеште. Мәдрәсәдә яткнда булган һәммә вакыйгаларны сөйләштеләр, көлештеләр. Алар бетте, инде килеп җитте сүз

---

[1]*Хөсне занына* –яхшы уена, матур фикеренә.

[2]*Хилаф* – каршы.

[3]*Тәкрар иттеләр* — кабатладылар.

Зәки мәхдүмгә. Кытрый хәзрәт үзенең укырга китергәнлегене белдергәч, мөдәррис Сәли бик шатланды, кәефләнде, соң дәрәҗә тырыштырып укытачагын да вәгъдә итте. Россиядә булган һәммә мәдрәсәләрне тәнкыйть итеп, үзенә бәрабәр һичкем вә һич мәдрәсә юклыгыны, әгәр дә Зәки тырышып укыса, ун сәнәдә[1] беренче мөдәррис булачагыны да аңлатты.

Кытрый мулла: «Нишләп бу сәнә мәдрәсәдә шәкерт бик аз күренә? Әллә җыелып бетмәгәнме әле?» — дип сорагач, Сәли хәзрәт: «Җыелып та бетмәгән бетүен, килгәннәре дә һәммәсе мәдрәсәдә түгел: кичәдән бирле минем утынымны кисәләр, егерме-утыз адәм шунда киткәннәрдер; шәкертләр фатиха аласылары килә!» — дип җавап бирде.

Ике хәзрәт һәртөрле бабтан[2] сүзләр сөйләштеләр, гәпләштеләр; мәҗлес бетте. Зәки мәхдүмгә мәдрәсәдән урын күрсәтү өчен, өчәүләшеп мәдрәсәгә дә килделәр. Вә, мәдрәсәнең һәртөрле урыннарыны тикшереп, Зәки шәкертнең мәхдүмлек хиссиятене нәзары игътибарда тотып[3], мәхдүмнәр, хәлфәләр вә хәлфәләрне ашата вә акчалар бирә торган бай балалары тора торган бер бүлмәдән урын бирделәр.

Зәки шәкерт алып килгән нәрсәләрене урынына китереп куйды. Шул урынга һәммә нәрсә вә киемнәрене куеп урнаштырды вә утырды. Димәк, Зәкинең шәкерт галәменә керү сәгатьләре, анасының йомшак тәрбиясеннән аерылып, гомумтатар шәкертенең күргән агырлыкларының һәммәсе Зәкинең башына да килә башлау заманнары җитте. Рәхәтлек сәгатьләренең соңы иреште. Атасы үзенең шәхси эшләренә вә Зәкинең кирәкләренә бетерде дә: «Угылым, саг бул, укы, тырыш, итагать ит!» — миселле вәгазьләр илә вәгазьләп, авылына китте.

Зәки мәдрәсәдә калды.

Атасы белән төш вакытында чәй эчкәннәр иде, шул чәйдән соң бичара Зәкигә бүген чәй, икмәк төсенә күрү насыйп булмады. Бер көн генә түгел, унбиш көнгәчә бер дә тамак туйганча аш, чәй күрмәде. Кайда икмәк ашап, кай заманда калган чәйдән берәр стакан салкын чәй эчмәк илә гомер үткәрде. Чөнки моңарча аслан[4] мәдрәсәгә йөрмәгән, мәдрәсәне күрмәгән, анасының хәзерләгәнене генә ашап йөргән, дөньяда үзең өчен аш пешерү бар икәнене дә яхшылап белмәгән Зәки кайда аш, чәй хәзерли белсен! Мәдрәсәдәге шәкертләр дә бу бичараның хәленә карап кызганмыйлар, бу ач бит, ашарга хәзерли белми бит, моңарга ярдәм идәргә кирәк, дип уйлый белмиләр.

Зәки, ачлык илә бу кадәрле кыенлык күрдеке кеби, әүвәлге көннән үк

---

[1]*Сәнәдә* — елда.

[2]*Бабтан* — мәсьәләдән.

[3]*Хиссиятене нәзары игътибарда тотып* — хисләрен игътибарга алып.

[4]*Аслан* — һич тә.

татар шәкертләренең мәдрәсәгә яңа килгән бичара яшьләргә кыла торган вәхшәтләрене дә күрә башлады. Әүвәлге көнене, ачлыктан ни эшләргә белмичә утырганда, хәзрәттә утын кисүчеләр кайтып, Зәки янына җыелышып, Зәкидән көләргә, юк-бар нәрсәләр сорашмага, төрле ләкабләр[1] такмага башладылар. Шулай мәсхәрә итеп утыралар иде, чалма-чапан киенгән бер өлкән адәм килеп керде. Бу адәм, кергәч, гүя белмәмешкә салынып: «Бу нинди шәкерт? Әй, малай! Син кем, кем угылы, син монда нигә килдең?» — дип сорашмага башлады. Зәки кәмаль тәгъзыйм[2] вә хәвеф илә генә ничөн килгәнлекене вә кем идекене бәян итте.

Бу чалмалы адәм бу сөальләр илә генә калмады, мәдрәсәгә һич тәгаллыкы булмаган[3] «Сезнең авылда карга бармы? Ничек кычкыра? Бозау дигән хайван була диләр, ул ничек була? Анаң ни исемле? Апаларың ничәү, исемнәре ничек?» кеби кирәксез нәрсәләрне дә сораша башлады. Бичара Зәки, бу сөальләрдән авыл егетләре сүзенең исе килгәнлекене уйласа да: «Ни чара, бер өлкән хәлфәдер», дип уйлап, һәммәсен тугрылык илә генә бәян итте.

Бу чалмалы адәм дә соңгы тәгаллыксыз сөальнең җавапларыны бер кәгазьгә язып алды. Зәки бу адәмне бер хәлфә дип уйласа да, бу явыз, Зәкине сайратыр өчен, юри шул кыяфәткә кергән бер ялганчы адәм иде. Бу соңгы җавапларны һәммә шәкерт бик диккать илә тыңлап, зиһеннәренә алдылар да соңра: «Зәки, каргача кычкыр әле, фәлән-төгән, апаң матурмы?» — дигән кеби сүзләр илә мәсхәрәли дә башладылар. Бердән, ачлык бәласе вә, бердән, шәкерт көлкесе илә бичара соң дәрәҗә боекты, эче пошты, кайгырды. Ләкин, нишләсен, шул атасы утыртып киткән урыннан кичке сәгать уннаргача кузгалмый утырды да халык ята башлагач ятты. Ачлык сәбәпле бер дә яхшылап йоклый да алмады. Иртә берлән дә һәммә халыктан алда уянып, һаман ачлыктан эчләрене шыкырдатып утырды. Бу көндә дә бер-ике стакан салкын чәйдән башка һични килмәде, бу көндә дә телсез, аяксыз адәм кеби шул урында боегып утырудан башка һични булмады.

Кич җитте, утын кисүче "рабочийлар" тагын дөбер-шатыр кайттылар. Бичара Зәки, бу бәдбәхетләр[4] кайткач: «Кичә дә мыскыл иткәннәр иде, бүген дә берәр эш кылмасалар ярар иде!» — дип куркып утыра иде. Әлеге рабочийлар тагын да җыелышып, Зәкидән көләргә, төрле исемнәр тагарга башладылар. Бер тарафтан шулай көлеп мәсхәрә иткәндә, икенче берәүләре, Зәкине тагын ныграк мәсхәрәләү өчен, бер уен чыгардылар. Бер өлкән

---

[1]*Ләкабләр* — кушаматлар.
[2]*Кәмаль тәгъзыйм* — зур ихтирам.
[3]*Тәгаллыкы булмаган* – бәйләнеше булмаган.
[4]*Бәдбәхетләр* – явызлар.

чикмәннең җиңеннән түшәмгә каршы тотып карыйлар да: «Бер йолдыз, ике йолдыз», — дип саныйлар, гүя йолдыз күренә, имеш. Үзләре бик күбесе карадылар, йолдыз санадылар да соңра Зәкигә дә йомшаклык илә генә: «Туганым, көн буена уйнамый, көлми боегып утырасың; кил, кара чикмән җиңеннән, анда кызык нәрсәләр күренә», — дип, Зәкинең башыны чикмән җиңенә тыктылар. Зәки башыны тыккач, җиңне түшәмгә каршы тотып: «Зәки, күренәме йолдыз?» — дип сорыйлар. Зәки: «Юк, күренми», — дигәч: «Сабыр, сабыр, хәзер күренер!» — дип җавап бирәләр иде. Озак та үтмәде, берсе карлы-бозлы салкын вә пычрак суны Зәкинең йөзенә җиң эченнән коеп та җибәрде. Бичара Зәкинең өсте-башы һәммәсе пычранды, суланды. Кызганыч Зәки, башыны киссәләр дә кулыннан һични килми, сабырдан башка бер чарасы юк, калтырап, туңып бер сәгать кадәр тавышсыз гына елап утырды.

Шулай итеп, бу көнне дә үткәрде. Кич булды. Ачлы-туклы булып тагын сәгать уннарда ятты. Азрак йоклады да, иртә торып, һаман кузгалмас бабай кеби урынында боегып утырды. Инде шулай да азрак ачылды, алай-болай сөйләшә башлады. Башка үзе кеби балалар илә аз гына көлә, уйный башлады.

Өйләдән соң үзе кеби кечкенә иптәшләре күз бәйләп кеше куа торган бер уен чыгардылар, Зәкине дә уеннарына чакырып алдылар. Ничә көннәр боегып утырган Зәки кызыгып кына уйнап йөргәндә, күзне бәйләү чираты аңар да килеп җитте; бәйләделәр. Зәки, бичара, ике кулыны җәеп, халыкны куып йөри башлады. Бу хәлдән истифадә итмәк булып[1], иптәшләре, идәннең баз капкачын ачып, шул турыга гына пычрак сулар, нәҗесләр белән тулган таз (ләгән) куйдылар. Бичара Зәки, тирләп-пешеп куып йөргәндә, ачык базга тугры килеп, чалт итеп нәҗес ләгәнгә килеп төште. Баз яхшы тирән генә иде. Әгъзасы да агыртты, ләгәндә булган нәҗескә һәммә киемнәре дә буялды.

Безнең бичара Зәки, ачлык илә эчләре шыкырдадыгы кеби, тәмам өйрәнеп җиткәнгәчә менә шундый вәхшәтләрнең һәммәсене дә күрде. Шәкертләр бик мәсхәрәләделәр. Йортыннан алып килгән нәрсәләрене урлап ашау, йоклагач мендәр вә юрганнарыны тартып алып китү, һәммә былчырак нәрсәләрне сөлгесенә сөртү, киемнәре илә идән себерү кеби эшләрне — хасил, татар мәдрәсәләрендә яңа килгән шәкерткә кылына торган һәммә вәхшәтләрне калдырмадылар, эшләделәр.

Бер ун көн-унбиш көн шул рәвешле авырлыклар күрде. Соңра Зәки мәхдүм дә өйрәнде: үзе, мәдрәсәнең төп шәкертләре арасына кереп, үги булучылыктан чыга башлады. Унбиш көнгәчә күргән авырлыкларыннан

[1]*Истифадә итмәк булып* – файдаланып.

кемгә шикаять итсә дә: «Яңа килгәндә азрак шулай була инде ул», — дигән сүздән башка һични ишетә алмыйча аптырап йөрсә дә, хәзер инде үзе шул вәхшиләргә кушылып, яңа килгән шәкертләрне изалый[1] башлады. Димәк, чын иске татар шәкерте булды. Зәки, өч җомга үткәч, «Шәрхе Габдулла»дан[2+] дәрес тә башлады.

Бу мәдрәсәдә биш-алты хәлфә булса да, һәммәсе шәкертне бүлешеп алып, һәр шәкерт үзенең хәлфәсеннән генә дәрес уку лязем булдыгыннан, Зәки ялгыз «Шәрхе Габдулла»ны укый, башка һични укымый, вә бу китапны да атнага бер йә ике дәрес кенә укый, чөнки Зәкинең хәлфәсенең шәкертләре бик күп улдыгыннан, тиз дәрес алырга чират йитми иде.

Хәзер Зәкинең эше җайланды, атнага бер-ике дәрес ала да, үзенең зирәклеге сәбәпле бик тиз белеп, башка заманда буш — укымый үткәрә; өйләгәчә аш пешерә, өйләдән соң ашап йоклый, кич берлә чиертке, карта, шатранҗ[2] кеби уеннарның берсе илә шөгыльләнә иде. Дәрес укып арткан эше булмаса да, һәртөрле уеннарда бик мәһарәт[3] хасил итте. Хосусән, карта, шатранҗларда бик шәп булды.

Зәкинең килгәненә бер айдан да артык булса да, шул озын заманда бер дә җеназа булмавы сәбәпле, шәкертләр: «Фәлән бай үлсә иде, фәләннең фәләне үлсә иде», — дип теләп, дүрт күз илә җеназаны көтә башлаганнар иде. Шәкертнең догасы мәкъбүл[4] диләр, дөрес сүз икән: бер көнне иртә берлән: «Фәлән байның фәләне үлгән, җеназа күтәрергә утыз шәкерт кирәк», — дип хәбәр иттеләр.

Менә шәкертләрнең дүрт күз белән көткән шатлыклы сәгатьләре килде. Бүген һәммә шәкерт шат, кәефле, көләч йөзле. Халь телләре илә[5]: «Эләктерәбез бүген фәләнчә акчаны», — дип кычкырып тора башладылар. Шул шатлыклар күтәрүгә язылган адәмнәр хакында бигрәк тә күп улдыгыннан, һәммә шәкерт: «Әй, шул утыз кеше эченә эләгеп булса ярар иде!» — дип тырышып, һәммәсе күтәрергә үзенең мөстәхикъ[6] идекене исбат итмәктә иде. Бу хосуста[7] күп сүз дә булды, талаш-сүгеш тә булды, азрак сугыш та булды. Ахырда, бу мөшкил мәсьәләне таләбә[8] үзара хәл итә алмыйча, Сәли хәзрәткә мөрәҗәгать иттеләр. Сәлигә дә һәркем үзене тиешле күрсәтә. Берсе: «Мин җәй көне дә мәдрәсәдә тордым», — ди. Берсе: «Җәй

---

[1]*Изалый* — кыерсыта, газаплый.
[2]*Шатранҗ* — шахмат.
[3]*Мәһарәт* — осталык.
[4]*Мәкъбүл* — кабул ителә.
[5]*Халь телләре илә* — «бөтен тавышларына, бөтен көчләренә» мәгънәсендә.
[6]*Мөстәхикъ* — хаклы.
[7]*Бу хосуста* — бу хакта.
[8]*Таләбә* — шәкертләр.

көне мәдрәсәдә торганнар җәй — шул вакытта — күп хосулланганнар[1], хәзер инде без күтәрергә кирәк, безгә тиеш» — ди. Бәгъзеләре: «Без мулла җәлял, тәүзыйхханнарны[3+] калдырып, вак малайларны җибәрмәкче буласызмы?» — ди. Мәсьәлә бик мөшкилләнде, таләбәнең каны кызды; шулай да гаюр[2] хәзрәт, таләбәнең ай-ваена карамый, мәсьәләне хәл кылды: үзенә бик итагатьлеләр вә бик күп хезмәт иткәннәрне сайлап, утыз адәмне язып чыгып китте. Өйлә якынлады.

Таләбәләр җеназага барырга һәммәсе хәзерләнә, салкыннан саклану өчен төрле киемнәр җыярга башладылар. Безнең Зәки мәхдүм җеназага бармадыгыннан, аның һәммә киемнәрене алдылар. Өйлә җитте. Һәммә шәкерт төрле-төрле кыяфәттә киенде; кайсылары өлкән чалмалар, чалмасы булмаганнар шарф вә сөлгеләрене башларына чалып, муеннарына вә колакларына кызыл яулыклар бәйләп, дөбер-шатыр чыгып киттеләр. Хәлфәләрдән башлап мәдрәсәдә яткан аяксыз хәерчеләргәчә — һәммәсе китте. Ялгыз Зәки калды да, бик каты авыру булдыгыннан, тагын бер шәкерт калды. Өйлә үтте, сәгать дүртләр булды. Шакыр-шокыр туңып, кызарышып, үлекчеләр кайттылар. Боларның кайтып керүләре белән мәдрәсәдә тагын тавыш башланды. Берсе әйтә: «Әнә, фәлән берлән икемезгә дип, бер сум биргәннәр иде, ул миңа бирмәде», — ди. Кайсы әйтә: «Әнә фәлән, утызның эченә язылмаса да, безнең илә утырып акча алды, аның акчасын бүләргә кирәк», — ди. Кайсысы байны сүгә: «Миңа аз булды», — ди; кайсысы: «Фәлән адәм мине урынымнан өстерәп чыгарды», — дип талаша; кайсы: «У-у-уу, туңдым, күкрәгемә, башыма суык үтте», — ди. Әлхасыйль[3], һәркем бер җирдә тавышлый вә үз кайгысын кайгырта.

Җеназа хакында булган тавышларны Зәкинең беренче күрүе улдыгыннан, ул соң дәрәҗәдә гаҗәпләнеп вә кызыкланып карап йөрде. Инде бу тавышлар да бетте, кайсы пичтә, кайсы казанда чаж-чож пешеренергә, алып кайткан акчаның рәхәтен күрергә башладылар. Пешерделәр дә, төшерделәр дә, ашадылар да җылындылар.

Кич булды. Караңгы төште. Караңгы төшкән соң, башка көннәрдә һич тә булмый торган хәлләр булды. Башка көннәрне тыныч кына йоклыйлар иде. Бу көнне әллә нигә һәммә шәкерт берәм-берәм генә урамга чыгып сыздылар.

Сәгать уникеләргәчә мәдрәсәдә шәкерт бик аз булды. Уникедән соң бәгъзеләре өстерәлеп кенә кайтып йоклады. Бәгъзеләре таң булгач кына

---

[1]*Хосулланганнар* — файда күргәннәр.

[2]*Гаюр* — гайрәтле.

[3]*Әлхасыйль*— кыскасы.

кайтты. Безнең Зәки хәзердә бу хәлгә бик аптыраса да, өлкәнрәк булгач, үзе дә шулай хосул[1] булган кичләрдә сәяхәттән калмый башлады. Бүген иртәдән башлап кичкәчә «әлиф» дип дәрес укыган адәм булмады. Шулай итеп, никадәр таләбәнең озын бер көне зайгъ[2] булды.

Бу көн кыш буена бер генә булмый, һәр айга ничәшәр көн шулай үлек өчен укымый үткәрә; ашка барып, Коръән чыгарга барып үткән гомерләр хисапсыз күп була. Бер кеше җенләнсә, җиде шәкертнең җиде көне мотлакан[3] зайгъ була. Җеназа көне үтте үтүен дә, инде шәкертләр басылып укырмы? Хәер, җеназадан да әһәмиятлерәк бер эш якынлашты. Хәзер шәкертләр: «Аллага шөкер, рамазан[4] җитә, унбиш кенә көн калды», — дип шатланышып сөйләшә башладылар.

Унбиш көн дә үтте. Шәкертнең дүрт күз илә көткән көннәре җитте. Рамазан керде, һәммә шәкертнең агызында: «Бүген ифтарга[5] кемнәр бара? Вә кем чакырган? Вә кайчан зәкят[6] керә?» — дигән сүзләр генә ишетелә башлады. Ифтарга егермене чакырса — утыз, утызны чакырса кырык баралар иде. Ифтар хакында низаг чыккан көннәр аз булмый иде. Шул араларда кергән зәкят дәхи[7] күп вакыт низагларга мөфзый булды[8]. Менә керә зәкят! Моны бүләргә кирәк. Ничек бүләргә: мөсавәт[9] иләме, дәрәҗә иләме? Күп сугыш вә кычкырышлардан соң, пишкадәмнәр: «Безнең «Мулла Җәлял»[4+] укуымызның шул вакытта да файдасы тимәгәч», — дип, мөсавәткә риза улмый, дәрәҗә илән тәкъсимгә[10] мәҗбүр иттеләр.

Рамазанның уннары җитте. Инде мәсьәләнең бигрәк тә әһәмиятлесе — хәтем көне якынлашты. Унберендә хәтем булачак! Һәммә таләбә шул хәтемне генә сөйли: «Кайчан унберенче көннең акшамы җитәр? Алгы сафка утырып булса ярар иде, йа алла, ничек алгы сафка эләгергә? Күпме акча төшәр икән? Биш-ун сум төшсә ярар иде! Фәләнчә сум төшсә, ун тиен сәдака бирәм яки бер Коръән чыгам», — сүзләре һәммә таләбәдән ишетелмәктә вә гомум таләбә “Иза Вакугать» сүрәсене[5+] тәкрар-тәкрар укымакта иделәр. Анларның фикре галиләренчә[11], моны күп укыган адәмгә акча күп эләгә, имеш.

---

[1]*Хосул* – керем.

[2] Зайгъ — әрәм.

[3]*Мотлакан* — һичшиксез, шиксез.

[4]*Рамазан* — ай елының тугызынчы ае исеме.

[5]*Ифтарга* — уразада авыз ачу мәҗлесенә.

[6]*Зәкят* — шәригать законы буенча керемнең 40 сумнан 1 сумын фәкыйрьләргә, руханиларга бирү.

[7]*Дәхи* — тагын.

[8]*Мөфзый булды* — илтте.

[9]*Мөсавәт* — тигезлек.

[10]*Тәкъсимгә* — бүлергә.

[11]*Фикре галиләренчә* — югары фикеренчә.

Көтелгән унберенче көн тугды. Бүген һәммә шәкерт алгы сафка эләгү өчен хәйлә эзли: «Акшамнан[1] кайтмаенча фәлән бүлмәгә качып калырга кирәк; кесәгә булки алып барырга кирәк; иптәш, син алгы сафка керсәң, урынны киңрәк ал, мине дә сыйдырырсың», — кеби сүзләр сөйләнмәктә иде. Һәммә таләбә өлкән чалмалар хәзерләмәктә, чалмасы кечерәк булса, астына сөлге урап, өлкән ясамакта; һәр тарафтан хәтемдә киеп утыру өчен чапаннар алып килмәктә иделәр. Шул рәвешле хәрәкәт иң кечкенәләрдән башлап иң өлкән хәлфәләргәчә тәгаммем иткән[2], һәммәсе кызу-кызу хәзерләнә иделәр. Һичкемнән: «Алгы сафка эләгеп буламы? Күпме төшәр?» — дигәнгә башка һични ишетелми, соң дәрәҗә иҗтиһад берлән, бөтен дөньяны ут алса да, тукталу ихтималлары юк кеби хәрәкәттәләр иде.

Акшам җитте. Елында бер кәррә[3] сәҗдә итмәгән шәкертләр дә, өлкән чалма киеп, мәсҗедкә барырга хәзерләнделәр. Мәдрәсәдә күп яткан пишкадәмнәр вә хәйләле яшьләр, халык акшамнан чykканчы нәфел намазы[4] укып калырга да, халык чыккач, алгы сафны эләктерергә уйлап, акшамга кесәләренә күмәч тыгып киттеләр. Вә бик күбесе, акшамга бармаенча, мәсҗедтән халык чыгып беткәнне мәдрәсә капкасы төбендә көтеп тордылар да, халык чыккач, дөнья җимерелгән кеби дөбер итеп, бер минут эчендә мәсҗетнең ишеге төбенә тыгылдылар.

Һәркем, алгы сафка керергә тырышып, ишектән элек кермәкче булдыгыннан, ишеккә бик тыгызланып кысылдылар. Безнең Зәки мәхдүм дә, белмәенчә шулар арасына тыгылып, тынны алалмаслык булып кысылган: «Йа Ходаем, үләмме, каламмы? Бер әгъзам изеләме?» — дип,ник килгәненә үкенмәктә иде. Башка шәкертләргә дә бу ишек кылдан нечкә, кылычтан үткен булды: «Башымны, изәсез, аякны сындырасыз, кулымны чыгарасыз; алла, корсакны тиштеңез! Уф-уф, үтердеңез!» тавышлары бер ун минуткача ишетелде. Бу тыгызлыктан котылып киткәннәре, аяк киемнәрене салмый-нитми, туры әүвәлге сафка яшен кеби атылмакталар иде. Безнең Зәки дә ничек булса да алгы сафка эләкте. Кызганыч! Бичара бик күп шәкертләрнең каты газаплanulары бушка чыкты, һәммәсе алгы сафка эләгә алмадылар.

Намаз якынлашты. Аяксыз, сукыр, кулсыз, телсез хәерчеләр һәммәсе дә шәкертләрнең артындагы сафка тыгызланып тулдылар. Бу ике нәүгъ[5] хәерчедән соң халык та җыела башлады. Килгән бер адәм: «Бу ни гаҗәп! Башка көннәрне намазга бер-ике генә шәкерт килә иде, бүген ничә сафларга бик иртә шәкерт килеп тулган!» — дип аптырамакта иде. Бәгъзеләре дә: «Ул

---

[1] *Акшамнан* – ахшамнан.
[2]*Тәгаммем иткән* — барысын да биләп алган, бердәй булган.
[3]*Кәррә* — тапкыр.
[4]*Нәфел намазы* — мәҗбүри булмаган, савап өчен үтәлгән өстәмә намаз.
[5]*Нәүгъ* — төрле.

хәерчеләр һәр елда шулай: хәтем көнне акча өчен генә акшамнан ук киләләр, башка көнне асла күренмиләр дә», — дип сүкмәктә иделәр.

Халык та җыелды, намаз башланды. Шәкерт утырган сафлар шулкадәр тыгыз иде, егерме кешелек сафка алтмыш-җитмеш шәкерт утырган, әгәр дә ялгыш берсе сафтан чыгып калачак булса, һич тә керүе мөмкин түгел. Һәммәсе, бер каткан җисем кеби, бергә ята, бергә тора; әгәр дә сәҗдәгә барганда[1] берсе генә артта калса, шып итеп урыны бикләнә дә ике саф арасында кала иде. Бичара Зәки шул кадәрле газапланды, изелде ки, гомерендә бу сафка кермәскә ант итте.

Ни булса булды, намаз бетте, дога да башланды. Кари[2] әфәнденең: «Биля хисаб вә ля газаб җәннәткә идхал әйләя[3]! төгән әйләя!» — кеби сүзләреннән соң гомум җәмәгать «амин!» дип кычкыра; безнең шәкертләр, «амин» дигәндә дога кабул була, имеш, дип белдекләреннән, халыкның «амин»ының алдыннан гына: «Йа Алла! Фәләнчә сум бир!» — дип әйтеп алалар иде.

Дога бетте. Халык та түгәрәкләнеп утырдылар. Садака өләшенә башлады. Хилкага[4] эләгә алмаган шәкертләр ике кулларыны хилкадагы адәмнәрнең ике ягыннан сузып утыралар иде. Гүя байлар, икесен ике адәмнең кулы дип, икесенә дә акча салачак, имеш! Ни төшсә дә төшкәндер, садака бетте. Халык кайта башлады. Безем шәкертләр дә мәдрәсәгә кайттылар. Шәкертләрнең кайсы бик шат, кәефле, көләч йөзле; бәгъзеләре бик кайгылы: «Бәдбәхет фәлән адәм алгы сафка кертмәде, фәлән бай бер генә тиен бирде», — дип сукранмакталар; «сиңа күпме» дә «сиңа күпме», — дип сорашалар иде. Шалдыр-шолдыр акчалар санаштылар, ашадылар-эчтеләр дә ишек төбендә алгы сафта күргән кыенлыкларыны вә агыруларыны[5] бетерү өчен урамга таралдылар. Бигайниһи[6] җеназадагы хәлләр монда да булды.

Инде хәтем дә үтте. Бу хәтем өчен дә шәкертләрнең берничә көннәре укымыйча узды. Безнең Зәки мәхдүм, электән бу хәлләрне һич күрмәдегеннән, кәмаль тәгаҗҗебләә[7]: «Бу шәкертләр нигә бер дә оялмыйлар? Ничөн акча өчен бу кадәрле тырышалар икән?» — дип гаҗәпсенеп йөри иде. Бу хәлләр Зәки өчен акчасыз бер кәмит иде.

Шәкертләр, хәтем мәсьәләсене онытып, азрак укый башлаганнар иде,

---

[1]*Сәҗдәгә барганда* — бу урында Коръән укыганда җиргә йөз белән иелү.

[2] *Кари* – Коръәнне яттан укучы.

[3] *«Биля хисаб вә ля газаб җәннәткә идхал әйләя»* — «хисап алмыйча һәм газапсыз гына Алла сине оҗмахка кертер» мәгънәсендә; Коръән сүрәсенә туры китереп язылган.

[4] *Хилкага* — тезелеп утырган кешеләр түгәрәгенә.

[5]*Агыруларыны* — авыртуларын.

[6]*Бигайниһи* — нәкъ.

[7]*Кәмаль тәгаҗҗебләә* — бик гаҗәпләнеп.

гаед якынлашты. Шәкертләр, тагын да укудан сүрелеп, ярты гомерләрене гаед сөйләп үткәрә башладылар. «Гаед тизрәк җитсә иде, фәлән иде», — дигән сүзләрне тәкрар итә башладылар. Гаедкә җиде көн калды. Шәкертләр гаед өчен азат та ителделәр.

Безнең Зәки рамазан буена да бер дә яхшылап укымый йөргән иде. Инде бигрәк тынычлап, көннәрен шаярып кына уздыра иде. Башка шәкертләр: «Гаедтә ничек күбрәк келәнергә, ничек күбрәк акча җыярга, бу ярминкәдә ничек күп файда итәргә кирәк?» — дип юл хәзерләп, гаед өчен тырыша башладылар. — «Иптәш, гаедтә кем берлән йөрисең? Мине дә бергә алып йөрсәңче!» — «Юк, иптәш, үзем дә фәләннәргә генә ияреп йөримен». — «Иптәш, гаедкә ничә генә көн калды! Без шәһәрдә булган байларның йортларын белеп куярга кирәк; нинди урамда нинди байлар бар, һәммәсене дә белеп, язып куярга кирәк!» — мисле сүзләр күп шәкертнең агызыннан ишетелмәктә иде. Бигрәк иҗтиһадлы булганнар, вывеска таныйрлык адәмнәрне алып, монда бай бармы-юкмы идекене капка башыннан карап, онытылмасын дип язып алып йөриләр һәм: «Әүвәл фәләнчәгә, соңра фәләнчә байга барырга кирәк», — дип программалар да төзеп куялар иде.

Гаед якынлады. Шәкертләр “Иза Вакугать” сүрәсенә бигрәк тәкрар укый башладылар. Шәкертләрдән каюсы байларның йортыны эзли, каюсы үзенә иптәш эзли, каюсы гаедтә байларга күренү өчен чапаннар алып килә башладылар. Фәкать безем Зәки мәхдүм байларның йортын да белми, буе да өлкән түгел, шул сәбәпле аны берсе дә катыштырмыйлар да. Үзе дә катышырга теләмәде.

Шәкертләрнең дүрт күз илә көткән гаед таңы туды, “Иза Вакугать”не бик күп укып, намазга киттеләр. Зәки дә бергә китте. Намаз укып кайттылар да, алай-болай итеп, гаедкә дә киттеләр. Зәки, үзенең өендә өйрәнгәнчә бер шатлык көн хисаплап, гаедкә китте. Гаед укыдылар да, безнең Зәки тәмам шатлык илә генә мәдрәсәгә кайтты. Мәдрәсәгә кереп: «Иптәшләр кайткач фәлән итәргә кирәк, тәмле нәрсәләр алып, чәй эчәргә кирәк», — дип уйлап, иптәшләрене көтеп тора башлады.

Гаедтән кайтканга байтак вакыт булды. Зәки ялыгып бетте: «Нигә болай кайтмадылар? Әллә берәр бай һәммәсенә чакырып алып киттеме икән? Әллә мин, ялгышып, намазны бетермәенчә кайттыммы икән?» — дип, бик уйлана вә аптырый башлады.

Бичара Зәки көнозын шулай ялгыз уларак мәдрәсәдә утырды. Мәдрәсәгә Зәкигә башка шәкерт кайтканы да, күренгәне дә булмады. Фәкать яшен кеби кызуланып үтеп киткән ак башлы нәрсәләр генә тәрәзәдән күренеп кенә кала, башка һични юк.

Кич булды, ясигъ[1] җитте. «Уф Алла, ардым, хәлем бетте», — дип, акрын-акрын гына шәкертләр кайта башлады. Сәгать унике булганча һәммәсе дә соң дәрәҗә арып кайттылар. Гүя көнозын таш кискәннәр. Бу кайтканнардан Зәки сорый: «Сезнең һәммәңезне алып киттеләрме? Нишләп гаед көнне мәдрәсәдә, бер кәррә генә улсын, кайтып, рәхәтләнеп чәй эчмәдеңез?» Шәкертләр әйтә: «И туган, туган! Син яшь әле, белмисең: ярминкәнең бу әүвәлге көне шулкадәрле әһәмиятле, мәдрәсәгә кайтып чәй эчү түгел, атамыз үлсә дә илтифат итү[2] ихтималымыз юк. Ни җаның берлә мәдрәсәгә кайтып вакыт уздырмак кирәк!» Бу сүзләрне ишетеп, безнең Зәки дә кызыгып-кызыгып куя: «Ахрысы, бик зур хөрмәт вә илтифат итәдер байлар, юкса болай ихласлы улмаслар иде. Әллә икенче гаедтә үзем дә йөримме икән?» — дип тә хыяллана, уйлана башлады. Урамнарда этләр кеби чабышып, һәммә байларның ишекләре төбенә барып: «Әссәламегаләйкем, гаедләр мөбарәк улсын!» — дип йөрүләрене, моңа каршы: «Китеңез, чалмалы хәерчеләр, адәмгә әһле илән ашарга да вакыт бирми, ишек кагып йөрисез! Оятсыз вә инсафсызлар», — дип сүгелүләренә вә бәгъзеләренең полицә илә куылуларыны бичара Зәки белми иде. Әгәр дә бу хәлләрне белсә, мәдрәсәдә күп ятмау сәбәпле вөҗдан вә хәясы бозылмаган[3] Зәкиебез бу шәкертнең вөҗдансыз вә хәясызлыгына хәйран калыр иде.

Сәгать уникеләр булгач һәммәсе аһ-ваһлашып кайтып йокладылар. Безнең Зәки дә йоклады. Зәкине уятучы булмадыгыннан, сәгать сигезләргәчә йоклады. Сигездә торса, күрә: шәкертләрдән җилләр исә. Зәкигә башка һичбер шәкерт калмаган. Чәй эчү-нитү юк, торганнар да тагын байлар ишеге төбендә кул кушырып торырга таралганнар. Бу көн Зәки шәкертләрнең юклыгына бик гаҗәпләнмәде. «Кайда булсын, байлар ишегене кагарга чыкканнардыр», — диде дә куйды.

Чәйне эчеп, азрак йөреп тә керим дип урамга чыккан иде, кайда гына караса да, башлары ап-ак чалмадан дүрт-биш шәкертнең чапкан аттай йөгергәннәре күрде. Бәгъзеләреннән, туктатып, берәр нәрсә сорамакчы булса да, кайда Зәки илән сөйләшеп вакыт үткәрү: «Туганым, бер минуты да бик кыйммәт тора: зинһар, безне туктатма!» — дип кенә җавап бирәләр иде.

Бүген дә, гаеднең өченче көне дә, шулай мәдрәсәдә Зәкигә башка һичкем улмады. Озын өч көн шәкертләр урам буена чалмадан чабышып йөрделәр.

Өч көн үтте, гаед бетте. «Ай-һай, бу гаед бер җиде-сигез көн булса яхшы булыр иде! Бетте шул инде, нишлисең?» — дип, һәммәсе җыеларак,

---

[1]*Ясигъ* — шәфәкъ кызыллыгы беткәннән соң укыла торган ясту (бишенче) намазы вакыты.
[2]*Илтифат итү* – олылау.
[3]*Хәясы бозылмаган* — ояты качмаган, тыйнак.

гаедтә булган вәкаигъне[1] сөйләшә башладылар. Фәлән бай күпме бирде? Безгә бер тиен дә бирми, коры чәй генә эчерде; фәлән бай «оятсызлар» дип сүкте. Җәгъфәр агай малаеннан кудырып чыгарды. Бәшәри полицә илә кудырды. Бәкер: «Урамда чалма сатасыз!» — дип кычкырып калды. Фәлән байга кереп, чәй эчә башлаган идек, фәлән шәкерт, бай икенче бүлмәгә чыкканда, кесәсенә бер алма тыга башлагач, көзге васитасилә[2] моның алуын күргәннәр дә, эчә башлаган чынаякны эчермәенчә, «бәдбәхет караклар» дип куып чыгарды. Вә башка шундый бик күп хәкарәтләр[3] күргәнлекләрене һәммәсене мөфассалән[4] сөйләштеләр, көлештеләр.

Гаеднең атналары үтте. Тик торудан ялка башладылар. Ул арада хәзрәт тә кереп: «Күп яттыңыз инде, укый башларга кирәк», — дип чыгып китте.

Укый башладылар башлавын да, коры исеме генә шул! Алларына китапны ачып, бер-ике сүз әйтсә әйтә, әйтмәсә юк: тагын сөйләшергә керешә. Гаед, хәтем хәлләрене тәкрар итә. Чөнки атнага-унбиш көнгә бер дәрес; аны бер көндә укып belә дә, ундүрт көнене, башка эш булмагач, сөйләшеп үткәрә; шулай итеп гомерләр үтә, рамазаннар, гаедләр дә үтә. Зәки килгәнгә өч айлар да булды. Корбан гаедләре дә якынлашты һәм әүвәлге кеби үттеләр; гаедтә һәммә нәрсә булды.

Бу гаедтә Зәкине иптәшләре, кызыктырып, хәерчелеккә өйрәтмәкче булып алып чыкканнар иде. Шәкертләр бик кызу йөрдекләреннән, Зәки бик арыды. Гомерендә бер кәррә улсын, бер эшсез ятып, адәмнең капкасына бармаган хәялы, инсафлы Зәкиемез һәркемнең капкасын кагып, каюсыннан сүгелеп китәргә вә каюсыннан «вакыт юк, өйдә юк» дигән сүзләрене ишетеп йөрергә вөҗданы кабул итмәде. Шул сәбәпле: «Ачка үлсәм дә чалма киеп келәнеп йөрер хәлем юк, байның берничә капигы[5] өчен йөз суымны түгү вә кызару ихтималым юк», — дип кереп китте, йөрмәде.

Әүвәлге хәлләр һәммәсе дә булды. Бу гаед тә үтеп китте. Инде шәкертләрнең өлкән ярминкәләре бетте. Фәкать җеназа булыр дип кенә өмидләнеп тора башладылар. Җеназа булса, югарыда язылган кәйфиятчә[6], талаш, сүгеш вә дәрес укымаулар һәммәсе була иде.

Әүвәлге елларда Зәкиемез бу мәсьәләләрнең һәммәсеннән хариҗ[7] вә тамашачысы гына булмыш исә дә, — сохбәт мөәссир[8] диләр, чын сүз икән, — шәкертләрнең һәр заман шул хәерчелек мәсьәләсене бик яратып

---

[1]*Вәкаигъне* — вакыйгаларны.
[2]*Көзге васитасилә* — көзге аша.
[3]*Хәкарәт*ләр— кимсетүләр.
[4]*Мөфассалән* — җентекләп.
[5]*Капигы* — (копейка) тиене өчен.
[6]*Кәйфиятчә* — рәвешчә.
[7]*Хариҗ* — читтә.
[8]*Сохбәт мөәссир* — «сөйләшеп утыру, иптәшлек йогынты ясый» мәгънәсендә.

чәйнәүләре сәбәпле Зәки дә икенче-өченче елларда, хәя вә инсафны[1] бер якка ташлап, гайн[2] шул үзе: «Ничек болар оялмыйлар икән?» — дип аптыраган эшләрене һәммәсене эшли башлады. Хәерчелектән оялмый башлап, тәмам өйрәнеп җитте. Вакыйган[3], башка шәкертләр дә шулай, мәдрәсәгә килгәндә инсаф вә хәялы булалар да, шул шәкерт арасына катышу сәбәпле, инсафны ташлап, вөҗданнары сукырая, хәерчелекне кабул итә башлый. Иштә голәмамызның садакага бу кадәрле сәҗдә итүләре, аларның ярлылыгы сәбәпле генә түгел, бәлки мәдрәсәдә егерме сәнәдә алган тәрбияләре шулай каннарына хәерчелекне сеңдерүдән гыйбарәт булу сәбәпле, садака дигәндә җаныны, динене, милләтене аямаслык булалар.

Безнең Зәки мәхдүм ноябрьдә килгән иде. Аз заман «Шәрхе Габдулла»ны укыды. Бик күп уеннар өйрәнде. Хәя вә инсафыны вә булса да азайтты, хәерчелеккә мәел итә[4] башлады. Имде март җитте, кояш нуры дөньяны ямьләндерә вә матурлый башлады. Шәкертнең дә күбесе китә башлады, мәдрәсәдә бик азы калды. Безнең Зәки дә апрель башларында өенә кайтып китте.

Бу җәй үтте. Көз башланды. Октябрь числосы кереп, дөньяның матурлыгы бетә башлады. Октябрьнең соңгы көннәрендә Зәки яңадан мәдрәсәгә килде. Башка шәкертләр дә азрак килгәли башлады. Үткән ел үзе никадәрле кыенлык күрмеш исә, яңа килгәннәргә шуларның һәммәсене Зәки үзе татыттыра башлады. Бу сәнәдә дә Зәки кеби ничә шәкертләр шундый вәхшәтләр күрделәр. Вә ничә шәкертләр инсаф вә хәяларын хәерчелек вә тамгачылыкка[5] алыштырдылар. Бу сәнәнең дә хәтем, гаед, рамазан, җеназаларында шәкерт арасындагы хәрәкәт бер дә үткән елныкыннан ким булмады. Билгакес[6], хәерчелекне бу сәнә бигрәк тә тәрәккый иттерделәр.

Башка елларда хәтем көнне һәммә хәерчеләр вә башка мәдрәсәнең шәкертләре дә, мәсҗеднең алгы бүлмәсенә кереп, садаканы безнең шәкертләр илә уртаклашалар иде. Бу сәнәдә бу мәдрәсәнең шәкертләре байларның һәммә садакасыны үзләренә алып, башкаларга бирдермәү өчен хәйлә эзли башладылар. Бу хосуста һич укымаенча дүрт-биш көнне әрәм иттеләр. Күп кычкырыштылар, сөйләштеләр, мең төрле хәйләләр күрсәттеләр. Кайсы: «Урамга чыгып, һәммә халыкка, бер сүз җае чыгарып, хәтемнең булачак көненнән башкасыны әйтергә кирәк, шәкертләр һәм хәерчеләр хәтемне белми

[1] *Хәя вә инсафны* — тыйнаклыкны һәм гаделлекне.
[2] *Гайн* — нәкъ.
[3] *Вакыйган* — чыннан да.
[4] *Мәел итә* — авыша.
[5] *Тамгачылыкка* — ачкүзлелеккә.
[6] *Билгакес* — киресенчә.

калсын», — ди; кайсылары: «Ишек төбенә караучылар куеп, садакачы адәмнең үземездән башкасыны кертмәскә кирәк», — диләр. Вә башка шундый бик күп фикерләр сөйләнеп, күп сүзләр соңында, шул соңгы фикерне кабул итәрәк, җиде сумга ике шәкертне ишек төбенә каравылчылыкка ялладылар. Бу мәдрәсә шәкертләреннән башка һичбер садакачыны эчкә, бүлмәгә кертмәскә, хәерче яки чит шәкерт бирәү генә керсә дә, акча бирмәскә шарт иттеләр.

Бу каравылчылар бер җәһәттән безнең шәкертләргә дә зарар булды. Башка елларны күбесе акшамнан кайтмый кала, кайтканнары да, халык акшамнан чыгып бетү илә тиз үк барып мәсҗедкә тула иде. Бу каравылчылар акшамнан һич шәкертне калдырмый куып кайтардылар да, мәсҗеднең алгы бүлмәсенең ишегене бикләп, ифтар идәргә кайтып киттеләр. Акшамнан соң шәкертләр мәсҗедкә барып тулдылар, ләкин ни файда? Алгы бүлмә бикле, керергә юл юк.

Бераз соң каравылчылар килделәр. Ишек ачылды, һәммә шәкертләр утырды. Хәерчеләрнең икенче нәугысе — аксак, сукыр вә чулаклар килә башлады. Хәерчеләр килә дә, елдагы гадәтләренчә, алгы бүлмәгә керә башлый, каравылчылардан: «Бабай, сезгә бүген анда керергә ярамый», — дигән сүзләрне ишеткәч, бәгъзеләре: «Шәкертләр белмәенчә тыймыйлар, бер сер бардыр», — дип тукталалар; бәгъзеләре: «Гомердә мәнгы ителмәгәнне[1] бүген генә ничек мәнгы итәләр, ни өчен Алланың мәсҗеденә болар хуҗа булып, без зәгыйфьләрне мәхрүм итәләр», — кеби сүзләрне рәнҗеп кенә әйтәләр дә урыннарына утыралар. Бу эш шәкерт хәйләсе идекене төшенгәннәре шәкертләрне яндырып сүкмәктәләр, вә бәгъзеләре, сүгү илә генә калмаенча, көчлек илә кермәкче булып, шәкертләр илә тартыша башлый иде.

Шул тартышучылар арасында бер авыру хәерче бар икән. Күп тарткалаша торгач, авыруы кузгалып, тәмам җансыз хәленә килде. Аягы, кулы вә һәммә әгъзасы катып, тәмам үлде диярлек булды. Бу хәл бөтен халыкны хәрәкәткә китерде. Тавыш купты: «Ни бар да ни бар?» «Моны кем үтерде?» — «Кем булсын, әнә чалмалы хәерчеләр, садаканың чын әһле улан зәгыйфьләрне мәхрүм итеп, үзләренә генә алу өчен ишеккә ике зобани[2] куйганнар. Шул зобанилар әллә нишләтеп авыруыны кузгаттылар», — дип һәммә халык сүкмәгә башлады.

Бер тарафтан, шул хәлдән истифадә идәрәк, хәерчеләр дә алгы бүлмәгә керү өчен һөҗүм итмәктә, вә каравылчы шәкертләр дә, үзләренә акча бирелмәүдән куркып, хәерчеләрне кертмәү өчен соң дәрәҗә иҗтиһад итмәктә

[1]*Мәнгы ителмәгәнне* — тыелмаганны.
[2]*Зобани* — сакчы мәгънәсендә.

иделәр. Әллә нинди сүгелүләргә дә илтифат итмәделәр. Бу сәнәдә әллә никадәрле зәгыйфь хәерчеләрне кан-яшь түктерделәр. Ни булса булды, хәерчеләрне асла кертмәделәр. Һәм яхшы гына файда да иттеләр. Елдагыдан күбрәк садака эләкте.

Шәкертләр, бу сәнәдә моның файдасыны күргәч, һәр елда да шулай садаканы үзләренә генә алу өчен ишеккә каравылчы куймый калмадылар. Гаед, җеназа вә рамазаннарда да әүвәлге еллардагыдан хили тәрәккъкый иттерделәр[1]. Садаканы ничек күбрәк җыю тугрысында күп мөшавәрәләр[2] иттеләр вә күп низамнар[3] яптылар. Юкарыда сөйләндеге кеби, безем Зәки дә, сохбәтнең тәэсире сәбәпле, инсаф вә хәяны ташлады, чын хәерче, садакачы вә тамгычы булды. Бер Зәки генә түгел, башка бик күп яшьләр дә хәяны ташлап, хәерчелеккә иялә́нделәр, шәрган вә гакълән[4] хәрам улан хәерчелекне бер фарыз эш кеби эшләргә өйрәнделәр.

Бу хәерчелек вә садакачылык мәсьәләсе шәкерт арасына яңа фикер вә ислахы мәдарис[5] фикере вә милләт кайгысы керә башлаганчы тәрәккъкыйның ниһаятенә ирешмеш исә дә, шәкертләр, бу фикергә керә башлагач: «Бу хәерчелек вә сәдакачылык кеби хурлык эш юк, бу эш шәрган вә гаклән безгә хәрам», — дип уйлый башладылар.

Зәкинең сәдакачылыктагы мәһарәтене күрдек.

Инде моны ташлап, мәдрәсәдә ниләр укыды вә ниләр белде? — шул хакта азрак сөйлик. Безнең Сәли мулла: «Тырышып укыса, ун елда мулла вә мөдәррис булыр», — дигән иде. Зәки мәхдүм ун ел гына түгел, унике-унөч еллар да кәмаль иҗтиһад илә укыды вә шәкертләр арасында беренче булды. «Шәрхе Габдулла»дан башлаган иде, ике сәнәдә моны чыгып, нәхүдән[6] кавагыйд[7], гавамил миәт[8], «Әнмүзәҗ»[6+] , «Мулла Җами»[7+] китапларыны да бик иҗтиһад илә биш сәнә укыды вә боларны гадәттә укылачак кадәрлесене укып бетергәч, мантыйк[9] башлады. Мантыйк башлады димәк — Зәки өчен икенче бер галәмә керде димәктер. Мантыйк башлагач, һәммә хәлләре үзгәрде. Дәрес укулар да бик башкаланды. Әүвәлдә дәресне тиз генә алалар иде дә чыгып китәләр иде. Хәзер исә бер дәрес алу өчен азында бер көн кирәк, чөнки дәрескә керәләр дә йә бик озак моназарә[10] вә сүгешү илә

---

[1]*Хили тәрәккъкый иттерделәр* — байтак алга киттеләр.
[2]*Мөшавәрәләр* — киңәшләшүләр.
[3]*Низамнар*— кагыйдәләр.
[4]*Шәрган вә гакълән* – шәригать һәм акыл буенча.
[5]*Ислахы мәдарис* – мәдрәсәләрне яңарту.
[6]*Нәхүдән* — синтаксистан.
[7]*Кавагыйд* — грамматик кагыйдәләр.
[8]*Гавамил миәт* — сүз төрләнеше.
[9]*Мантыйк* — логика.
[10]*Моназарә* — бәхәсләшү.

үткәрәләр, йә дә боларны укыткан Заһи хәлфәнең: «Фәлан меллага болай дидем, алай дидем, сүктем, берни белмисең, агач дидем, фәлан мөдәррис сөйләшә башлаган иде, агызыны да ачтырмадым», кеби шапырынуларыны вә бөтен татар голәмасыны надан ясап, үзенең галимлегене күрсәтүләрен тыңлап, безнең хәлфә бигрәк галим икән дип, рәхәтләнеп утыралар; вә дүрт сәгать дәрестә утырсалар, ике сәгатене шундый юк-барны сөйләп үтә иде.

«Мантыйк файдасы моназарә белән генә табыла, моназарә кылышмаган адәм мантыйкны белә дә, аңлый да алмый; кәмаләт[1] анчак[2] моназарәгә оста булучылыктан гыйбарәт», кеби, моназарәгә мәхәббәт иттерә торган сүзләрне һәр дәрестә хәлфәсе сөйләп чыгардыгыннан, моназарәләрне хәлфәләр мактый дип, безем Зәки дә моназарә өчен соң дәрәҗә тырышты. Белсә дә, белмәсә дә, өстәл сугып акыруга өйрәнә башлады.

Шәкертләр арасында иң мактаулы вә яхшы эш — белсә дә, белмәсә дә, хата булса да, тугры булса да, үзенең алга алган сүзене ташламау, хатасыны игътираф итмәү улдыгыннан, безнең Зәки дә үзенең сүзене бирмәскә, әллә нинди ялган, хата, булса да, шул сүз өчен кычкырышырга вә тукталып калмаска бик иҗтиһад итә, тавышы беткәнчә кычкырыша вә сүгешә иде. Сүгешкән саен шөһрәте вә абруе арттыгыннан, һәммә шәкерт Зәкине мактый башладыкларыннан, Зәки бигрәк тә моназарәгә мәхәббәт куйды. Аллаһы биргән һәр көн иртә тора да моназарә вә сүгешүгә башлый вә һәр көн бишалты кеше илә сүгешмәенчә калмый иде.

Бара торгач, Зәкигә сүгешү табигый булып китте. Зәки моназарәгә вә сүгешүгә мәхәббәт вә кәмаль иҗтиһад илә «Исагуҗи»дан[8+] башлап «Шәмсия»[9+], «Сөлләм»[10+], «Тәһзиб»[11+] , «Гакаид»[12+], «Тәүзыйх»[13+]вә «Мулла Җәлял»ләргәчә укыды. Үзенең зирәк вә тырышлыгы вә моназарәчелеге сәбәпле бу мәдрәсәнең иң галим вә иң беренчеләреннән булды. Үзенең фаразынча, хәзердә Зәки мәхдүмгә беленмәячәк һич гыйлем юк. Моннан соң Зәки өчен һич гыйлемне остазга утырып укуның кирәге юк, нинди генә гыйлем булса да, үзе карап беләчәк иде.

Зәкинең шөһрәте бу мәдрәсәдә генә калмады, башка мәдрәсәләргә дә җәелде: Зәкигә моназарәгә килә вә үзене дә моназарәгә чакыра башладылар. Бу шәһәрдә ничә мәдрәсә булса, һәммәсенә дә барды, сөйләште, галәбә итте[3]. Ялгыз «Гыйльмия»[14+] дигән бер, ысулы җәдидә берлән укыта торган мәдрәсәгә: «Анлар берни белми, берни аңламый», — дип бармый иде. Зәкинең бәхетенә каршы, әллә нинди бер эш чыгып, атна кичне «Гыйльмия»

---

[1]*Кәмаләт* — тулылык, өлгереп җиткәнлек.
[2]*Анчак* — бары тик.

[3]*Галәбә итте* — җиңеп чыкты.

мәдрәсәсенә барырга тиешле булды. Вә теләр-теләмәс барды.

Шәкертләр чәй хәзерләделәр, сөйләштеләр. Зәкинең күңеле булсын дип җиңел генә сүз дә сорадылар. Бик мөлаем мөгамәлә иттекләреннән, Зәки боларны бик яратты. Шәкертләр дә һәр атнада килүен үтенделәр. Зәки шулай һәр атнада килә башлады. Утыра, сөйләшә, шәкертләрнең сүзене тыңлый иде. Шәкертләр дә Зәкинең гомерендә ишетмәгән яхшы-яхшы гына фикерләр, вакыйгалар сөйлиләр вә уен тарызында[1] гына дөньяның килешеннән азрак бәян итәләр иде.

Зәкинең «Гыйльмия» мәдрәсәсенә барып йөргәнене остазы Заһи ишетеп, Зәкине: «Анда баргач юк-бар сөйләшмә, ник мантыйк укымыйсыз? Җәгърафия, тарих, тәфсирләр[2] ник укыйсыз? Адәм анларны мантыйк белгән соң үзе дә белә, анларны укырга кирәк түгел дип сөйлә», — дип котыртып җибәрде.

Зәки атна кич барды. Сөйләшә башладылар. Зәки, урынсыз булса да: «Ник аны укыйсыз? Ник фәләнне укымыйсыз?» — дип, уку хакында сүз ачты.

Шәкертләрнең асыл максудлары да шул иде. Бу хосуста ничек сүз чыгарырга белмиләр иде. Зәки үзе башлагач, бик шатланарак, укуларны тәнкыйть итә башладылар. Сүз арасында шәкертләр Зәкидән сорыйлар:

— Мәдрәсәгә килгәнеңезгә ничә ел?

Зәки:

— Унбиш ел.

Шәкертләр:

— Ниләр укыдыңыз?

Зәки:

— Сарыф[3], нәхү, мантыйк, кәлям[4], ысул[5], фәраиз[6] һәм азрак мохтәсар[7] укыдым.

Шәкертләр:

— Тәфсир, хәдис, сияреннәби[8], тарих дини[9], фәлсәфәи диния[10], хисап, җәгърафия, тарих гомуми, һәндәсә[11] шикелле нәрсәләр укыдыңызмы?

---

[1]*Тарызында* — рәвешендә.
[2]*Тәфсир* — Коръән сүзләренә аңлатма.
[3]*Сарыф* — морфология.
[4]*Кәлям* — сөйләм культурасы турында дәрес.
[5]*Ысул* – кагыйдәләр.
[6]*Фәраиз* — варисларга мирасның күпме тиюен билгели торган кагыйдәләр.
[7]*Мохтәсар* — шәригать законнарын кыскача аңлатучы китап.
[8]*Сияреннәби* — Мөхәммәд пәйгамбәрнең холыклары, гадәтләре, тормышы турында язылган китап.
[9]*Тарих дини* — дин тарихы.
[10]*Фәлсәфәи диния* — дин фәлсәфәсе.
[11]*Һәндәсә* — геометрия.

Зәки:

— Һи, сез кызык икәнсез, бу дәресләрне кеше остаздан укып утырамыни? Анларны мантыйк белгән кеше укымыйча да белә.

Шәкертләр:

— Сез менә мантыйкны кирәк кадәрдә укып бетергәнсез, шул без әйткән нәрсәләрне белерсезме икән?

Зәки:

— Ник белмәскә? Һәммәсен дә белерем.

— Яхшы, алайса без тәфсир, хәдистән сорап карыйк!

— Юк, мин: «Китаптан карасам беләм», — дидем, минем зиһенемдә бар дип әйтмим.

Бу тугрыда сүз озынга китте. Шәкертләр:

— Ул, китаптан караганда гына белү — «гыйлем билфигыль»[1] түгел, бәлки «гыйлем билкувә»[2] генә була бит, — диделәр.

Зәки дә һаман үз сүзендә дәвам итеп:

— Китаптан карагач белсәң ярый ул, — дип, күп сүзләр сөйләде.

Ахыр шәкертләр Зәкига юл куйдылар:

— Әнә, сез дигәнчә булсын, караганда белү җитсен, менә без сезгә бер китап биреп карыйк, белерсезме икән? — диделәр.

Зәки дә: «Белермен, белермен», — дип, мөтәкәббиранә[3] торды. Шәкертләр «Тәфсире кәшшаф»[15+] китерделәр. Зәки дә карарга тотынды. Ләкин, бичара, тиз заман тиргә батып: «Әхтәри»[16+] бирегез әле, «Мулла Җами» китерегез әле», — дигән шикелле сүзләр сөйли башлады. Шәкертләр дә: «Тагы хәлфәгезне дә китермикме?» — дип, берсен дә бирмиләр иде.

Зәки шулай да үзенең белмәвен игътираф итмәде[4]: «Мин лөгатьне генә белмимен, «Җаһилел-лөгати мимма лягаеб»[5] диләр, лөгатьне белсәм, барыны да беләмен», — дип, күп кычкырышты. Фәкать шәкертләр тиешле генә сүзләрене әйтәләр дә, Зәки илә кычкырышмыйлар, тик көлемсерәп кенә утыралар иде. Шәкертләрнең максуды Зәкигә бер фикер бирү улдыгыннан, Зәкинең күңеле калмасын дип, ничек тә тырыштылар. Соңра, азрак кына Зәкидән сүз сорап, Зәки тарафына галәбәлекне дә калдырдылар. Зәкинең мантыйк хакындагы игътикады[6] бик аз гына булса да йомшарды. Мәдрәсәсенә кайткач, бу хәлне мөфассалән[7] Заһи хәлфәгә сөйләде.

---

[1]*Гыйлем билфигыль* — төпле, чын гыйлем.

[2]*Гыйлем билкувә* — кеше үз сәләте, хәзерлегенә нисбәтән генә алган гыйлем.

[3]*Мөтәкәббиранә* — масаеп.

[4]*Игътираф итмәде* — танымады.

[5] *«Җаһилеллөгати мимма лягаеб»* — «сүзлек белмәү (башта тотмау) гаеп түгел» мәгънәсендә.

[6]*Игътикады*— ышанычы.

[7]*Мөфассалән* — җентекләп.

Берничә атнадан соң Заһи хәлфә үзе: «Шул шәкертләрне эт итеп сүгеп кайтыйм әле» – дип, «Гыйльмия» мәдрәсәсенә барды.

Шәкертләр хәлфәне каршыладылар. Чәй хәзерләделәр, һәртөрле бабтан сүз башлап карасалар да, Заһи хәлфә һич тә яхшылап сөйләшмәде, ничек булса да уку мәсьәләсене уртага чыгарды. «Мантыйк, кәлям генә уку кирәкме, әллә югарыда зикер иделенгән[1] голүме диния[2] илә фөнуне җәдидә[3] дә кирәкме?» Бу хосуста һәр ике тараф күп сүз сөйләде. Кыскасы, Заһи хәлфә сүзенчә, мантыйк беленсә, башкасы укымый да беленә. Шәкертләр: «Мөмкин түгел», — диделәр.

Шулай кызулап сөйләшеп утырганда безнең Зәки мәхдүм дә килеп керде. Зәки килгәнене күргәч, Заһи хәлфә бигрәк котыра башлады. Эчкән кеше кеби өстәл сугып: «Сез берни белмисез, надансыз!» — дип кычкыра башлады.

Шәкертләр моңарча инсаф үзәренә[4] вә ригая итеп[5] кенә сөйләшәләр иде. Заһи хәлфәнең бу вәхшиятене күргәч, ригая-фәләнне ташлап, хак сүзне бик ачы уларак сөйли башладылар.

— Мантыйк белгән адәм башкасыны укымый да белә дисең, үзең кырыктан узгансың; моннан соң белә торган заманың түгел, белгәнне өйрәтә торган заманың, дин голәмасына белү лязем улан[6] голүмне беләсеңме? — дип, Заһидан бик күп әсасе динияйә гаид[7] мәсьәләләрдән, хәтта пәйгамбәремезнең сияре[8] вә тарихларына кадәрле сорадылар.

Заһи хәлфә һәммәсенә сөкүт[9] яки сүгеш белән җавап бирә, һаман да җәһаләтене игътираф итми:

— Мин боларны караганым юк, карасам, беләмен, — дип кычкыра иде.

Шәкертләр дә:

— Иллегәчә карап белмәгәнне, күп булса ун-унбиш ел гомерең бар, инде ничек белерсең, — диләр иде.

Сүз күбәйде, өлкәнгә китте, тарафәен[10] дә ригая итүне ташладылар. Шәкертләр, Заһи хәлфәне башкача канәгатьләндерә алмагач, алдына тәфсир, хәдис, сиярләрне китереп ташладылар. Хосуси бәхәсләрне моталәга итеп[11] бирүне үтенделәр.

---

[1] *Зикер иделенгән* — искә алынган.
[2] *Голүме диния* — дин гыйлемнәре.
[3] *Фөнуне җәдидә* — яңа фәннәр.
[4] *Инсаф үзәренә* — әдәп белән.
[5] *Ригая итеп* –хөрмәтләп.
[6] *Лязем улан* — тиеш булган.
[7] *Әсасе динияйә гаид* — дин нигезләренә кагылышлы.
[8] *Сияре*— әхлагы.
[9] *Сөкүт* — дәшми калу.
[10] *Тарафәен* — һәр ике як.
[11] *Моталәга итеп* — тикшереп хөкем чыгару.

Хәлфә җәнабләре дә, лөгать белми, игърабны[1] да яхшы белми, бәлягать фәненә даир[2] сүзләр чыкса, бигрәк тә аптырап калса, «Мулла Җами», «Әхтәри», камус[3] сорый башлады. Шәкертләр: «Юк, — диләр, китермиләр, — һәрвакыт боларны өстерәп йөрерсеңмени?» — дип көлеп тә куялар иде. Шәкертләр, сүзнең соңында, ибтидаи балаларга[4] белү тиеш булган тарихен-нәбине[5], голүме диниянең әсасене[6] да белмәдекене, хәтта мохтәсарны да шәкертләренә тәрҗемә карап дәрес бирдекене — һәммәсене бик ачык Заһига сөйләделәр. Хәлфә моның илә дә җәһаләтене белмәде; белсә дә, гыйнадта[7], инкярдә[8] улды исә дә, бу соңгы мәҗлес Зәкигә ничә айлар әдәбият укып алмаячак фикерне урнаштырды. Дөньяда беренче галим дип уйлаган Заһиның бу кадәрле җәһаләтене күреп, мантыйкка булган мәхәббәте тәмам нәкыйсланды[9]. «Мантыйк укысак, башкасыны беләмез» дәгъвасене вөҗданы, гакылы кабул итми башлады. Бу мәҗлестә Заһига әйтелгән сүзләрнең хакмы-юкмы идекене бик тирән уйлый башлады. Вә һәр атнада шул шәкертләр янына бара вә аларга барган саен голүм, мәгариф вә милләт хакында сүз ача башладылар; вә Зәкигә һәртөрле романнар, «Миръат»лар[17+], «Тәрҗеман»нар[18+] бирәләр. Зәки дә боларны бик ләззәтләнеп укый, мәгълүмат ала иде.

Шул мәҗлестән соң Заһи хәлфә Зәки мәхдүмне мәдрәсәи «Гыйльмия»гә катышмаска вә анлар белән сөйләшмәскә әмер итдегеннән, Зәки үзенең анда баручылыгыны бер дә белдерми, алып килгән әдәбиятларыны да кеше күргәндә укымый башлады. Әүвәл заманда сәгать уникедән соң, кеше яткач, «Мәвакыйф», «Мәүләви Хәсән», «Хәмидулла»лар[19+] карый иде. Хәзер шул заманнарда «Мәвакыйф» эченә салып әдәбият һәм тарих карый башлады. «Мантыйк укысак, барыны беләмезме икән-юкмы икәнлегене бик тирән уйлый башлады. Үзе мантыйкны укыган, яхшы белгән булса да, тәфсир, хәдисне вә башка китапларны моталәга итеп белә алмаганлыгын бик яхшы төшенде.

Рисаләләрдән[10] татар шәкертләренең наданлыгыны, мәдрәсәләрнең начарлыгыны, ничә ел гарәп теле укысалар да, нә сөйләргә, нә язарга белмәүләрене, дин дә, фән дә белмәүләрене бәян иткән мәкаләләрне күреп,

---

[1]*Игърабны* — сүзләрнең төрләнешен, сүзләрне тәнвиннәре белән язу, уку.

[2]*Бәлягать фәненә даир* — сөйләүдә яки язудагы матурлык, тулылык, төзеклек турындагы фәнгә бәйләнешле.

[3]*Камус* — сүзлек.

[4]*Ибтидаи балаларга* — башлангыч мәктәп балаларына.

[5]*Тарихен-нәбине* — пәйгамбәрләр тарихын.

[6] *Әсасене* – нигезен.

[7]*Гыйнадта* — үзсүзлелектә, кирелектә.

[8]*Инкярдә* — кире кагуда.

[9]*Нәкыйсланды* — кимеде.

[10]*Рисаләләрдән* — китаплардан.

Зәки мәхдүм үзенең булган мәдрәсәсендәге укышны, үзенең иптәшләренең никадәрле нәрсә белгәнлеген тикшерә башлады.

Зәки уйлый: «Мин үзем биш-алты ел гарәп теле генә укыдым, мин аны беләмме?» — дип үзенең хәлен тикшерә. Берничә татар сүзене гарәпчәгә әйләндереп әйтмәкче була, — йә лөгать[1] тапмый, йә җөмлә итеп әйтә алмый; аннан соң гарәпчә язып карый, — юк, аны да булдыра алмый. «Гыйльмия» шәкертләре гарәп гәзитәсе биргәннәр иде, шуны моталәга итеп карый, — юк; «җа», «кам» кебиләрдән башка һичбер сүзгә төшенми. «Әхтәри» берлән карап карый, — бер юлны укыганча бер сәгать вакыт үтә. Хәлфәсе әйткәнчә, «Әхтәри»дән карап белү җитсә, бер гәзитәне ничә ай укымак кирәк? Зәки, бу мәдрәсәнең беренче шәкертләреннән була торып та, ничә ел укыган гарәп телене генә дә белмәгәч вә гарәп китапларыны гына да аңламагач, бу мәдрәсәләрнең начарлыгына тәмам канәгать хасил була. «Мантыйк беленсә, башкасын укымый да беләләр, голүме диния вә фөнуне җәдидә кирәк түгел; мантыйк, мохтәсар вә «Тәүзыйх» кына кирәк», дигән сүзләрне аз гына гакылы бар адәм кабул итмәячәгене яхшы гына төшенә. Бер тарафтан, «Гыйльмия» шәкертләре илә сөйләшеп, әдәбият укып вә, бер тарафтан, мәдрәсәдәге шәкертләрнең хәлләрен карап, укуларының бик начарлыгыны, мәдрәсәләр ислахка соң дәрәҗә мохтаҗ идекене төшенә башлый, хәтта аңлап җитә.

Мәдрәсәләрнең начарлыгыны, ислахның лөзүмене[2] Зәки мәхдүм яхшы аңлаган булса да, бу сәнәдә гомум таләбәгә бу фикерне белдермәде. Остазларыннан бигрәк яшерде. Фәкать беркадәрле истигъдадлы[3] таләбәләргә генә бу тугрыда байтак сөйләде вә анларны да азрак төшендерде.

Яз булды, Зәки кайтып китте. Ул бу җәйне бар гомерен әдәбият укып вә һәртөрле зыялы вә фикерле адәмнәр илә сөйләшеп үткәрү сәбәпле, Зәки бик яхшы фикер хасил итте. Көз көне мәдрәсәгә килгәндә, остазларының ай-ваена карамаенча, гомум шәкерткә ислах лөзүме вә мәдрәсәләрнең начарлыгы хакында сүз сөйләячәкмен, мантыйкның астыны-өсткә китерәчәкмен дип, кулларыны сызганып килде.

Мәдрәсәгә килүе илә укышларыны тәнкыйть итәргә вә, бу дәресләрне ташлап, заманага муафикъ рәвештә итеп голүме диния вә фөнун укырга кирәклегене сөйләргә башлады. Зәкидә, табигый уларак, сүзгә вә төшендерүгә осталык һәм дә кешене ригая итмәүчелек бар иде.

Шул сәбәпле шәкертләр арасына бик җиңел ислах фикере тарала башлады. «Ислах кирәк түгел, шул укыган гыйлемнәремез безгә җитә, артык

---

[1] *Лөгать*— бу урында сүз мәгънәсендә.
[2] *Ислахның лөзүмене* – үзгәртүнең кирәклеге.
[3] *Истигъдадлы* — сәләтле.

һични кирәге юк», дигәннәргә бер дә башкача исбат итеп маташмый, тота да шул шәкерттән үзенең дәрәҗәсенә мөнасиб[1] бер нәрсә сорый гына иде. Нәхү тәмам иткән адәм булса: «Алты ел сарыф, нәхү укыдың, башка милләтләр ике ел укып та гарәпчә сөйләргә һәм язарга гарәпнең үзе кеби беләләр; син алты елда ни белдең, менә фәләнчә-фәләнчә сүзләрне гарәпчәгә әйләндереп сөйлә һәм яз; йә булмаса әнә шәригең[2] илә гарәпчә сөйләш», — дип кенә әйтә иде.

Бичара шәкерт нишләсен, сөйли дә белми, яза да белми. Кулына бер гарәп гәзитәсе бирә. Аны да укый белми, гаҗизен[3] икъràргa мәҗбүр була. Әгәр хәтме көтеб кылырга[4] хәзерләнеп йөргән пишкадәмнәр булса: «Сез, дин гыйлеме беләмез, дингә хезмәт итәмез дип, унбиш-егерме ел укыдыңыз, истинҗа[5], хәез[6], никах, талакка башка[7] ни нәрсә беләсез? Менә исламга вә нәбиемезгә шул рәвешле тел тидерәләр, шул ифтираларны[8] ничек дәфгы итәсез[9]?» кеби күп сөальләр вә бәхәсләр күрсәтә һәм, карасак, анларның барыны беләмез дисәләр, хәдис, сияр, тәфсир китапларыны кулларына бирә: «Сөйләп бирегез», дия иде.

«Мәкамәте Хәрири»нең[20+] бер мәкаләсене бичара шәкертләр ничә көн камус вә «Әхтәри» карап та чыгара алмадылар. «Бохари»[21+], «Тәфсире Кәшшаф» кеби вәкыф[10] китаплар тузанга буялып ята иде. Хәзер бу китаплар шәкерткә ислах фикерене бирү өчен күп ярдәм иттеләр. Шәкерт боларны карый да: «Мантыйк белсәм, башкалар беленә», — дигән дәгъваның бер буш хыял идекене төшенә иде.

Зәкинең ислах фикерене таратуда бер коралы — тарих, җәгърафия иде. Яшьләрдән башлап пишкадәмнәргәчә булган һәммә шәкерттән: «Нәбиемез кайда яшәгән? Аның яшәгән җире нинди җир? Дөньяның кайсы тарафында? Нәбиемез заманында ислам кайда чаклы таралды? Аннан соң нинди җирләр мөселманнар кулына керде? Хәзерге заманда мөселманнар нинди урыннарда вә нинди кешеләр кул астында яшиләр? Хәлләре, тормышлары яхшымы?» — кеби нәрсәләр сорый иде. «Нәбиемез ничәнче елда туган? Кайсы сәнәдә пәйгамбәр булган? Исламны ничек тараткан? Ничә ел гомер иткән, кәйфияте

---

[1]*Мөнасиб* — туры килерлек.
[2]*Шәригең* — иптәшең.
[3]*Гаҗизен* — хәлдән килмәвен.
[4]*Хәтме көтеб кыйлырга* — укып тәмам итү.
[5]*Истинҗа* — тәрәттән соң, пакьләнү.
[6]*Хәез* — күрем.
[7]*Талакка башка* — хатын аеру ише нәрсәләрне белүдән башка.
[8]*Ифтираларны* – яла ягуларны.
[9]*Дәфгы итәсез* — кире кагасыз.
[10]*Вәкыф* — берәр кеше тарафыннан җәмәгать файдасына мәчеткә бирелгән мал, милек.

һиҗрәт[1] ничек, кәйфияте мәвет[2], сәнәи мәвет[3] кайчан? Аннан соң ничек интихабе хәлифә[4] булды? Соңра мөселманнарның хәлләре ни рәвешле булды?» — Хасил, ибтидаи сыйныфта белү лязем улан сөальләрне сорый вә моның җавабында бик гаҗәп сүзләр ишетә иде.

Муллаҗәлялханнардан да татар шәкертенең җәһаләтенә хәйран калырлык сүзләр ишетелә иде. Фөнун хакында да шәкертләр башта «хәрам» дигән сүз берлән генә бетерсәләр дә, фөнуне мәгарифтә алларына сәләфләрнең нә дәрәҗә тәрәкъкый итдекләрене бәян иткән тарих китереп салгач, тагын да оялалар, «фөнун хәрам» дисә, гомум сәләфне[5] сүгү була, «хәрам» димәсә, лөзүме ислахны[6] игътираф итү була. Менә шулай итеп, уен-көлке тарикы илә[7] ислах фикерене Зәки мәхдүм шәкерт арасына тарата. Тарафдарлары да көннән-көн күбәя бара иде.

Зәки бу сәнәдә моназарә дигән нәрсәне агызына да алмый; мантыйкны да аз укый, укыса да, файда алыйм дип түгел, бер дә укымасам, хәлфәләр мәдрәсәдән куар да иптәшләрем шул иске мунча, иске ташка разый булып калырлар дип кенә укый иде.

«Мәвакыйф», «Мәүләви Хәсән», «Хәмидулла» кебиләрне уку, карау түгел, нөсхәләрене дә капчыкка тутырып өенә җибәрде. Бу сәнәдә Зәкинең иң беренче максады — шәкерт арасына ислах фикерене тарату иде. Икенчесе — һәрдаим моназарә вә сүгешү илә әхлакы бик бозылган, газыб[8], хиддәт[9], хәсәд[10], гадавәт[11], гыйнад[12], мөкябәрә[13] вә тәгассыб[14] — һәммәсе Зәкигә табигый улучылык дәрәҗәсенә ирешкән иде. Бу сыйфатлар инсанга шәрган вә гаклән кабих вә мөһлик[15] идекене бик ачык белдекеннән, анларны ташларга соң дәрәҗә тырышкан улса да, һаман да тәмам ташлый алмаганлыктан, яңа фикергә керә башлаганнан бирле, борын моназарә сәбәпле бозылган әхлакны төзәтү өчен соң дәрәҗә иҗтиһад итә иде. Бу

---

[1]*Кәйфияте һиҗрәт* — «Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккәдән Мәдинәгә күчеп барган чагындагы хәлләре» мәгънәсендә.

[2]*Кәйфияте мәвет* — үлем хәле.

[3]*Сәнәи мәвет* — үлгән елы.

[4]*Интихабе хәлифә* — хәлифәлеккә сайлануы.

[5]*Гомум сәләфне* — барлык борынгы бабаларны.

[6]*Лөзуме ислахны* — яңару тиешлеген.

[7]*Тарикы илә* — ысулы, юлы белән.

[8]*Газыб* — ачу.

[9]*Хиддәт* — кискен холык.

[10]*Хәсәд* — көнчелек.

[11]*Гадавәт* — дошманлык, күрә алмау.

[12]*Гыйнад* – тискәрелек, үзсүзлелек.

[13]*Мөкябәрә* — эрелек, мин-минлек.

[14]*Тәгассыб* — фанатизм.

[15]*Шәрган вә гаклән кабих вә мөһлик* — шәригать һәм акыл буенча да әшәке һәм хәтәр.

кышта схоластиканың нәҗес әсәрләре[1] калмасын дип, соң дәрәҗә иҗтиһад итте.

Бичара Зәки үзенең наданлыгыннан бигрәк әхлакының бозылуы өчен артык дәрәҗә кайгыра иде. Әллә ни бер сәбәп беләп арада сүз башлана да, Зәкинең өйрәнгәнчә каны кызып китеп, әүвәлге шикелле, сүгешеп тә ташлый вә, бу хәлне үзе башта белмәенчә калса да, сүгешеп беткән соң, бу кадәрле тырышып та түзәлмәслек итеп әхлакыны моназарә бозган икән, ихтыярсыз вә белмәенчә сүгештерә дип, артык дәрәҗә вөҗданы газаплана иде. Инсанның кәмаләте анчак хөсен холык илә[2] улдыгыны яхшы белдегеннән, үзенең моназарә вә искечелектән күргән хурлыклары өчен күзеннән канлы яшьләр түгә иде.

Шул әхлаксызлык илә бәрабәр татар шәкертенең җәһаләтене дә күз алдына китереп, һич урынында утыра алмый, эш эшли алмый, шәкертләр янына барып, ислах фикерене сөйли башлый иде.

Безнең Зәки шул дәрәҗәдә иҗтиһад итте ки, аш янында булсын, дәрескә җыелышып ултыргач булсын, йә башка йирдә булсын, һичбер сүз сөйләми вә кешедән сөйләтми, мәгәр ислахы мәдарис хакында гына сөйли иде. Бу иҗтиһадның сәмәрәсене[3] дә күрде.

Берничә айдан соң бик күп шәкертләр Зәкинең тарафдары вә мәсләктәше[4] улдылар. Зәки, үзенең фикере таләбә гыйндендә мәкъбүл уларак[5], үзенең тарафдарлары күбәйгәнне күргәч, гайрәтене тагын арттырды. Шәкертләргә сөйләү илә генә канәгатьләнмәде, Заһи хәлфә вә Сәли хәзрәтләргә дә сөйли башлады.

Болар никадәрле Зәкине ислах фикереннән кайтару өчен иҗтиһад иттеләр исә дә, файда улмады — остазлар тарафыннан мәнгы күргән саен гайрәте артты. Зәки һәр дәрескә кергәндә: «Безгә ник тәфсир, хәдис, сияр, тарих вә фөнуне җәдидә укытмыйсыз? Нигә бар гомеремезне схоластика, истинҗа, хәез вә ихтиляфат[6] илә зайгъ итәсез?» — дип сорый вә фөнуне җәдидәнең тиешлегене күрсәтә иде.

Зәкинең бу гыйлемнәрне сорауларына каршы остазлары хәзер: «Иҗтиһад мөнкариз[22+7], безгә Коръән вә хәдис берлән гамәл дөрест түгел, Имам Әгъзамның[23+] сүзе сарих[8] Коръәнә мөхалиф улса да, тәкълид фарыз[1]»,

---

[1]*Нәҗес әсәрләре* — пычрак эзләре.

[2]*Инсанның кәмаләте анчак хөсен холык илә* — кешенең камиллеге — тик күркәм холык белән.

[3]*Сәмәрәсене* — нәтиҗәсен.

[4]*Мәсләктәше* — дөньяга карашлары бер булу.

[5]*Таләбәгыйндендә мәкъбүл уларак* — шәкертләр каршында яхшы күренгәнлектән.

[6]*Ихтиляфат* — фикер башкалыгы.

[7]*Иҗтиһад мөнкариз* — «тырышлык күрсәтү беткән, сүнгән» мәгънәсендә.

[8]*Сарих* — ачыктан-ачык.

— дип кенә җавап бирәләр иде. Зәки, бу сүзгә артык дәрәҗә хәйран каларак: «Остазларым! Коръәннең мәгънә вә хикмәтләре чиксез дип, китапларда бар бит. Имам Әгъзам шул хикмәтләрнең һәммәсене алып бетергәнмени? Хәзердә Коръәндә безгә файдалы бернәрсә дә юкмыни? Әллә Имам Әгъзамның хөкемнәре Коръән вә хәдисне насих иткәнме[2]? Әллә юкса Алла вә нәби безем кебиләр аңламаслык итеп сөйләгәннәрме? Безгә дин гыйлеме дип, мохтәсар «Һидая»[24+] генә укытасыз, — Коръән, хәдиснең һәммә хөкеме шул икегә кереп беткәнме? Кереп бетмәгән дисәңез, боларда булмаган хөкемнәр безгә файдасызмыни? Бу мохтәсарлар куянның шулпасының шулпасы дигән кеби генә бит Коръәнгә нәзарән[3]! Сез ни өчен әсасе динне укытмый, бер адәмнең фикеренә ияртеп, әсасе диннән мәхрүм итәсез? Ярый алайса, Коръән, хәдис укытылмасын да, ничөн сияр, тарих укытмыйсыз? Боларны да файдасыз дисезме? Коръәннең кыйсеме әгъзамы[4] сияр, тарихел-әнбия[5] вә анларның файдасыз булулары лазем була бит, Аллаһы Тәгалә сүзенең файдасыз булуы лазем була бит. Аллаһы Тәгалә ни өчен Коръәндә сияр вә тарих зикер иткән[6], ни өчен пәйгамбәрләр кыйссасын сөйләгән? Алайса, ни өчен фөнуне җәдидәләрнең укытылуы өчен тырышмыйсыз? Боларны хәрам дисезме? Гомум сәләф фөнун илә иштигаль иткән[7]. Хәйрел-корун илә мәдех ителенгән[8] өч гасырда фөнун мөселманнар кулында булган. Хәрам булса, файдасыз булса, ничөн анлар иштигаль иткәннәр? Имам Әгъзамнар вә башка имамнар һәммәсе шул заманда булганнар, — ни өчен тыймаганнар? Хәрам вә файдасыз улса, анлар тыярлар иде». Вә башка шундый бик күп сөальләр сораса да: «Син белмисең, надан, ахмаксың», — җавабыннан башканы ишетмәгәч, тукталырга мәҗбүр ула иде.

Туктала дигәч тә, сез уйламаңыз билкөлли[9] ислах сорау фикереннән туктала дип. Икенче вакытны тагын ныклап керешә; өстенә бурыч итеп алган кеше шикелле, дәрескә керсә, остазларына ислах лөзүмен сөйли вә иптәшләренә һәртөрле роман, гәзитә вә тарих укыта. Кыскасы, ислах өчен бар көчене вә бар гомерене сарыф итә иде. Ислах өчен никадәрле кыенлык вә авырлыклар күрмеш исә дә, һәммәсене иптәшләремне сәгадәт галәменә чыгару вә бу хурлыклардан котылдыру өчен күрәмен дип, шатлык хисап итә иде.

---

[1]*Тәкълид фарыз* — ияру тиеш.
[2]*Насих иткәнме* — юкка чыгарганмы.
[3]*Нәзарән* — караганда.
[4]*Кыйсеме әгъзамы* — зур өлеше.
[5]*Тарихел-әнбия* — пәйгамбәрләр тарихы.
[6]*Зикер иткән* — телгә алган.
[7]*Иштигаль иткән* — шөгыльләнгән.
[8]*Хәйрел-корун илә мәдех иделенгән* — яхшы, хәерле гасырлар дип макталган.
[9]*Билкөлли* — бөтенләй.

Бичара Зәки ислах фикерне сөйли башлаганнан бирле остазлары тарафыннан бихисап золым вә ифтиралар[1] да күрде. Ислах фикерене сөйли башлаганнан бирү сүгелмәгән һичбер көн булмады. Алла биргән көн, урынлы булсын, урынсыз булсын, Зәкигә сүгелү лязем иде. Ислах кирәк фикерен таләбә арасына тарата башлаганчы, Зәки остазларының иң мактаулы вә иң сөекле вә абруйлы шәкертләреннән иде. Тәфсир, фән кирәк, схоластика вә ихтиляфат[2] илә гомерне үткәрергә ярамый дип сөйли башлаган соң, әүвәлге мактаулулар хурлыкка әйләнде вә әүвәлге абруйлар нәфрәт вә гадавәткә[3] әйләнде.

Әүвәлдә нәкадәрле мактаулы вә абруйлы исә дә, хәзер һәммә шәкерттән ким күрә башладылар. Зәки белән һичкем урамга-фәләнгә бергә чыгып йөрмәскә, мәдрәсәдә дә Зәки илә сөйләшеп утырмаска вә җыелган халык арасына кертеп, Зәкине бер сүз сөйләтмәскә; башкалар теләгәндә чыгып йөрүгә ихтыярлы булсалар да, Зәкинең әллә кемнәргә катышу, кыйраәтханәгә[4] вә көтепханәгә бару ихтималы булдыгыннан, вакытлы-вакытсыз чыкмаска вә сорап кына чыгарга вә башка шундый бик кысынкылыкларны маддә-маддә[5] язып, Сәли берлән Заһи имза идәрәк, гомум шәкертне җыеп, бер әмернамә[6] укыдылар. Вә монарга кем мохаләфәт итсә дә, ригаясез[7] җәзалар биреләчәк булды. Вә остазлары, Зәкинең һәр хәрәкәтене тикшереп, үзләренә хәбәр бирү өчен бик күп җасус[8] вә хәфийяләр[9] куйдылар. Зәкигә килгән бик күп хатны, үзенә бирмәенчә, ачып укыдылар вә утка яктылар вә, кайда гына барачак булса да, үзенә белдерми артыннан җасуслар җибәрделәр. Әгәр дә берәр зыялы адәмгә яки кыйраәтханәгә барганлыгы сабит булса[10] яки, көтепханәдән әдәбият алып, иптәшләренә таратканлыгы беленсә, бик ныклап җәза бирәләр; фәлән нәрсә югалды дип алдап, һәр заман Зәкидән башлап, башка ислахчыларның һәммәсен, гәзитә, әдәбият вә мәмнугъ[11] мәктүбләр юкмы дип тикшереп, кесә вә сандыкларыны актарып тордылар. Ислах хакында язылган кәгазьләр, бер сәтырдан[12] башлап гәзитә вә романнар һәммәсе конфисковать ителеп, табылган саен утка яга бардылар. Ничә, ничә кәррә Зәкинең сандыкларына аракы, тәмәкеләрне, үзенә белдерми

---

[1] *Ифтиралар* – яла ягулар.
[2] *Ихтиляфат* – каршылыклы булу, фикер башкалыгы.
[3] *Гадавәткә* — дошманлыкка.
[4] *Кыйраәтханәгә* — уку өенә.
[5] *Маддә-маддә* — аерым бүлекләп, пунктлап.
[6] *Әмернамә* — приказ.
[7] *Ригаясез* —игътибар итмичә, кайгыртусыз.
[8] *Җасус – шымчы.*
[9] *Хәфийяләр* — яшерен күзәтүче кешеләр.
[10] *Сабит булса* — мәгълүм булса.
[11] *Мәмнугъ* — тыелган.
[12] *Сәтырдан* — юлдан, язу юлыннан.

салып, соңрак: «Менә фәлән эшне эшлисең, имеш, сандыгыңда фәлән бар, имеш», — дип тикшереп, каты-каты җәзалар бирделәр. Вә атасына: «Угылың бозылды, кяфер, дәһри[1] булды», — дип хат язып, Зәкине атасыннан бик каты сүктерделәр вә мәдрәсәдә булган шәкертләрнең һәммә хокукыннан аны мәхрүм иттеләр. Зәки берлән башка шәкертләр аз гына җыелып сөйләшә башласа: «Ни кылмакчы буласыз? Нинди фәсад[2] чыгарырга телисез тагы?» — дип зур тавышлар күтәрделәр.

Зәкинең ислах фикере таратуына Сәли хәзрәткә караганда да Заһиның[*] эче поша иде. Ул, мәдрәсәдә (бүлмәдә) торганлыктан, шәкертләрнең ислах фикеренә авышканлыкларыны вә Зәкинең тарафдарлары көннән-көн артканыны үз күзе илә күреп, коты чыга иде. Заһи хәлфә соңгы көннәрдә бигрәк тә авыру була башлады. Көн буе мәдрәсә идәне уртасында арлы-бирле атлап[**], кырын-кырын йөргән кебек, төннәрдә дә уты сүнми, үзе дә ишеге төбеннән китми иде. Соңрак шәкертләр арасында иттифак[3] әсәрләре күренә вә үз мәкъсудларыны сорарга хәзерлекләр сизелә башлагач, Заһиның хафасы йөзенә кадәр чыга башлады. Чөнки ислах ителгән тәкъдирдә, Заһи белгән юнан сөэрләре[4], коруне вөста[5] схоластикалары мәдрәсәдән себерелеп, анлардан башканы белмәгән Заһи хәлфәгә дә, өч мендәр өстенә менеп, замир мәрҗигъләре эзләп[6], хашия[7] кәгазьләре актарып яту урынына тамак кайгысы төшәчәк иде. (Хәтерегездән чыгармагыз: Сәли кебек бай вә мәхәллә имамнарына дәрестән килә торган файдадан киселгән тәкъдирдә дә агырлык күрелмәсә дә, кырык яшенә кадәр хашия яфраклары актарудан башкага ярамаган, урынсыз, эшлексез Заһи хәлфәгә шәкерттән килә торган файдалар югалган вакытта мәгыйшәт итү[8] читен улачагын.) (Җитмәсә приговор да җыелмаган бит!) Шунлыктан Заһи хәлфә эшләрене ничек тә тизрәк өзәргә, шәкертләргә ислах фикере урнашып җитмәс борын Зәкине ничек тә мәдрәсәдән чыгарырга тырыша вә аңа төрле сәбәпләр эзли иде; алай-болай шәкертләр арасында җыелыш-фәлән күрсә, яннарына барып, үзе сүзгә катышкан булып, Зәкидән андый-мондый сүз чыкмасмы, чыкдисә, Сәлигә

---

[1]*Дәһри* — динсез.
[2]*Фәсад* — бозыклык.
[*]"Әлислах" газетасының 1908 ел 28 санында шушы урында авторның үз искәрмәсе бар: Әүвәлдә Мөбарәкҗан исеме белән йөртелгән хәлфәне хәзер Заһи дип асыл үз исеме белән йөртә башлыйм.
[**]*арлы-бирле атлап* – ("Әлислах", 1908, 28 сан) *"похаживать" итеп* дип бирелгән.

[3]*Иттифак* — берләшү.
[4]*Юнан сөэрләре* — борынгы греклардан калган нәрсәләр.
[5]*Коруне вөста* — урта гасырлар.
[6]*Замир мәрҗигъләре эзләп* — «китап актарып, грамматик формаларны эзләү» мәгънәсендә.
[7]*Хашия* — китап читендәге язмалар.
[8]*Мәгыйшәт итү — тормыш итү.*

әйтеп, кудырырга ижтиһад итә иде. (Иске мәдрәсәләрдә зур хәлфәләргә яман сүз әйткән өчен куылу мәшһүр гадәтләрдән берседер.)

Башка шәкертләр никадәр гөнаһлы улсалар вә никадәр начарлыклар кыйлсалар да, Заһига тарафдарлык күрсәтеп, шпионлык итеп котылалар иде. Шул сәбәпле иске фикерле һәм укудан дәрте сүнгән вә Зәкинең ислах фикерләрене озайта алмаган* шәкертләр арасында тәүфикъсызлыклар көннән-көн арта бара иде.

Зәкинең гүзәл фикерләре вә корган планнары сәмәрәсез калмады. Аның фикерләре никадәр тар араларда вә кыска-кыска гына җөмләләр илән сөйләнсә дә, чын күңелдән чыкканлыктан, әсәрле була вә урынына төшәр-төшмәстән тамыр җәя бара иде. Тугрырак фикерле һәм вөжданнары югалмаган шәкертләр арасында үзара бер «иттифак» та ясалды. Кыскасы гына, кечек кенә ислахчылар партиясе тугды. Озак та үтмәде, бу ислахчылар, үзләренең фикерләрен кәгазьгә җыеп, маддә-маддә ясап, Сәли хәзрәткә дә бирмәкче улдылар. Заһи хәлфә боларны никадәр оештырмаска тырышса да, булдыра алмады. Ислах тарафдарлары, үзләренең мәкъсудларыны язып, Сәли хәзрәткә гариза күндерделәр. Гаризаларында сораган нәрсәләре: тәфсир, хәдис, фәлсәфәи диния, мәган, ысулел-фикъһе[1], лисане гарәп[2], тарихе мөкаддәс[3] вә гомуми тарих, җәгърафия, хисап фәннәре иде. Аның өстенә моңа кадәр укыла торган мантыйк («Исагуҗи», «Шәмсия», «Сөлләм», «Тәһзиб» вә әллә никадәр хашияләр) дәресләрене калдыру — анлар илән гомер үткәрмәүне үтенүдән гыйбарәт иде. Гаризаның ахырында тәнбиһ[4] сурәтендә: «Әгәр дә үзеңез кәнде[5] ихтыярыңыз илән бу сораган нәрсәләрне кабул итмәсәңез, мөфассал иттереп, бөтен мәкъсудларымызны бәян итеп вә моңа кадәр укыткан дәресләреңезне файдасыз шәйләрдән[6] гыйбарәт икәнен дәлилләр илән исбат итеп, мәхәллә байларына вә әһле мәгарифкә гариза бирәчәкмез. Кыскасы, мәкъсудымызга җитәргә тырышачакмыз...» — дип язылган иде.

Сәли хәзрәтнең аштан кайтып керүенә шундый мисалда гариза китереп биргәч тә, тиз үк малай җибәреп, Заһи хәлфәне чакырып килергә кушты*.

---

**ислах фикерләрене озайта алмаган* – (Әлислах", 1908, 28 сан) *ислах фикерләренә "почва" була алмаган* дип бирелгән.

[1]*Ысулел-фикъһе — мөселман дине мәсьәләләре турындагы белем нигезләре.*
[2]*Лисане гарәб — гарәп теле.*
[3]*Тарих мөкаддәс — изге тарих.*
[4]*Тәнбиһ* — искәртү.
[5]*Кәнде* — үз.
[6]*Шәйләрдән* — әйберләрдән.

*Бу җөмлә "Әльислах"та (1908, 28 сан) түбәндәгечә:*Сәли хәзрәтнең аштан кайтып керүенә шундый мисалда гариза китереп биргәч тә, тиз үк самаварчы малайны (көндез хәзрәттә самавар куеп төндә мәдрәсәдә сабак укый торган шәкерт) Заһи хәлфәне чакырып килергә кушты.*

Заһи хәлфә, Сәли хәзрәтнең бик кирәкле** йомыш илән чакырганын ишеткәч, истибрага[1] чыгып барган җиреннән борылып, бүлмәсеннән җиләнен алып, бер җиңен киеп, икенчесен кияр-кимәстән, Сәли хәзрәткә китте. Шәкертләр-ислахчылар хәзрәт малаен, күз кысып читкә тартып алып, ник килгәнен сорашкач, өй алдына алып чыгып: «Сәли илән хәлфәнең сөйләгәннәрен түкми-чәчми китерсәң, сиңа... тиен акча бирермез», — дип, Заһи хәлфә артыннан йөгерттеләр. (Ул бичара куана-куана йөгереп китте. Чәй китергән булып, ни сөйләгәннәрен барысыны да тыңлап, ислахчыларга сөйләп... алды.)

Заһи хәлфә барып керү илән Сәли хәзрәт, кулындагы шәкертләр гаризасын аңа биреп:

— Менә болар нишлиләр, менә ниләр сорыйлар, җитмәсә, ахырына «байларга да бирәчәкмез...» дигәннәр. Бар, анлар белән эш йөрт инде. Ай, заман! Кая китте рәхәт вакытлар? Соң, нишлибез? Болай гына эш итеп булмый, уйлашырга кирәк. Менә сине шуның өчен чакырттым, ни дисең? Укып чык әле! — диде. Заһи хәлфә укып бетергәч, Сәли тагын:

— Соң, нишлибез? Син әйткәнчә, әллә шул Зәкине генә, ничек тә бер хәйлә тауыб*, куыйкмы? Әллә ислах сораганнарның барысын да куамызмы? Ничәү үзләре? Сана әле! — диде. Заһи хәлфә:

— Әллә хәзергә берсен дә кумый, байларга гариза биргәнче торып торамызмы? Мәхәлләнең нөфүзле[2] вә дәүләтле адәмнәре фәлән вә фәлән... байлар һәммәсе дә безнең сүздән чыкмаслар бит! Шәкертләрнең гаризасыны анлар кабул итмәсләр бит! Шәкертне куганда үземезгә күп җәһәттән тыныч, рәхәт улса да, фәләннәр шәкертләрне тәфсир, фөнун сораган өчен куып чыгарганнар, дигән сүзләрне ишетү дә безгә яхшы булмас!

Сәли (ачуланып, кызарып):

— Әмма, син, булмаган сүзне сөйлисең соң! Әгәр дә шәкертләр мәхәллә халкына үзләренең нинди гыйлемнәр укырга теләгәнлекләрене күрсәтсәләр вә шул рәвешле ислах лөзүмен сөйләсәләр, халык шиксез кабул итәр; безнең ай-ваемызга карамаслар. Моңарча байларның безнең сүздән чыкмаулары, шәкертләрне байларга яман күрсәтеп, дин бетерергә, кяфер, дәһри булырга йөриләр дип сөйләвемездән вә шулай халык алдавымыздан гына бит! Әгәр дә шәкертләр нинди гыйлем сораганлыгыны халык белсә, шик юк, шәкерт тарафына авышачаклар. Шәкертләр бит тәфсир, хәдис,

---

***бик кирәкле* – (“Әльислах”, 1908, 30 сан) *“экстренный”* дип бирелгән.

[1]*Истибрага* — бәвел итүгә.

*1912 елгы басмада авторда шулай бирелгән.

[2]*Нөфүзле* — сүзе үтемле, авторитетлы.

фәлсәфәи диния, сияр, тарихен-нәби, лисане гарәп, фөнуне җәдидә кеби гыйлемнәрне сорыйлар. Бу гыйлемнәрне мөкәммәл[1] белү кирәклегендә кемнең шөбһәсе бар? Ислахка беренче дошман синең берлән мин дә бу гыйлемнәрнең укылуы кирәклегене инкяр итмибез вә шәригать нәзарыннан тиешле дип беләмез. Безнең каршы торуымыз шәригатькә хилаф вә тиешсез улудан түгел, анлар дигәнчә ислах булса, бик яхшы була-булуын да, — безнең үземезә бик кыенлык була вә шөһрәтемез бетә, наданлыгымыз мәйданга чыга. Җә, шулай бит! Беләсең бит, ул дуңгызлар үзләренең мәкъсудларыны нинди оста вә килешле итеп исбат итәләр. Әнә Зәкиләр-фәләннәр ислах тугрысында сине дә, мине дә ничә кәррә агызымызга... тыктылар. Ислахны инкяргә агыз ачмаслык ясадылар, гаҗиз иттеләр. «Куй, сез белмисез, кяфер, дәһри булгансыз», — дип сүгеп кенә туктаттык бит. Әгәр дә шул телләре илә: — «Менә без фәлән гыйлемнәрне сорыймыз вә фәләнчә ислах сорыймыз», — дип мәхәллә халкына сөйләсәләр, шәкерт агызыннан бу сүзләрне ишетеп, шөбһәсез, ислах лөзүмене аңларлар вә безне ислахка мәҗбүр итәрләр. Хәзердә бу шәкертләр бозылган дип йөрсәләр дә, шәкерт агызыннан тәфсир, фөнун ишетсәләр, җаннарын фида итәрләр. Син мәхәллә халкы безнең кулда, безнең сүземездән чыкмаслар дип уйлама! Анлар шәкертнең ни сораганыны белмәдегеннән генә безгә ияреп йөриләр. Әгәр дә үзләренең чын мәкъсудларыны шәкертләр белдерсәләр, синең берлән миңа: «Кулыңыздан килсә, менә шул гыйлемнәрне укытыңыз, кулыңыздан килмәсә, мәдрәсәдән үкчә күтәреңез», — диячәкләр. Безгә башка чара юк: йә куып чыгарамыз, йә дә мәнафигы шәхсиямезә[2] хилаф улмастай рәвешчә генә ислах итәмез. Ислах безнең өчен бик зарарлы булса да, нишлик соң? Ихтыярсыз уларак ислах итәрмез.

Заһи (бик мискинанә):

— Уф, Алла! Белмим шул, анлар дигәнчә ислах булса, эшемез бик яман. Алай соң мәнафигы шәхсиягә хилаф улмастай вә үземезнең рәхәт вә сәгадәтемезне бетермәстәй ислах мөмкинме? Шәкертнең сораганыны бирсәк, дөнья илә бәхилләшү лазем булмасмы?

Сәли:

— Уйлап карыйк әле. Анларниләр сорыйлар? Тәфсир, хәдис, сияреннәби, тарихен-нәби, фәлсәфәи диния, лисане гарәп, хисап, җәгъфрафия, тарих гомуми, тагын берничә нәрсәләр бар имде. Анларны оныткандмын. Менә шул гыйлемнәрне синең берлән мин укытырга лязем була. Бу гыйлемнәрне без укыта алырмызмы? Бонларны укыта башласак, укыта белмимез дип тагын да сөйли башламасалрмы? Без кырык яшемезгәчә бар

---

[1]*Мөкәммәл* — тулы.
[2]*Мәнафигы шәхсиямезә* — үз файдабызга.

гомеремезне мантыйк, моназарә вә ихтиляфат укып үткәрдек. Кырыктан соң шул укыганнарымызны укытамыз. Шәкертләр сораганнарны гомеремездә укыганымыз вә яхшылап караганымыз да юк. Мин үзем, шәкертләр авызыннан «тәфсир, хәдис» тавышларыны ишеткәч, бик муафикъ күреп: «Тукта әле, тәфсир, хәдис кеби гыйлемнәрне укытырлык итеп төшенеп була микән? Әгәр дә яхшы белсәм, тәфсир укытырмын», — дип, тәфсир, хәдискарый башлаган идем, «Сөлләм Казый»ларыны[25+], «Мәвакыйф» вә «Мирза»ларны[26+] бик яхшы аңлаган булсак та, боларны белеп булмый икән. Әллә нинди «тәшбиһ[1], мәҗаз[2], киная кылып» кеби сүзләр очрый. Бунларны «Әхтәри», камустан да тауып булмый. Бер ай буена бик тырышып карадым, бер-ике бит Коръәнне дә яхшы белә алмадым. Бер сәхифәне карап чыгу өчен «Әхтәри», камус карап башым катып бетте. Тырышып-тырышып та булдыра алмагач, тәфсир, хәдистән дәрес әйтү мөмкин түгеллегене төшенеп, ислахка каршы тора башладым. Без бунлардан шәкертләрне канәгатьләндермәячәкмез. Дәхи дә сияр вә тарихе дини сорыйлар. Мин бу гыйлемнәрне кеше агызыннан гына ишеткәнем бар; юкса, караганым да, укыганым да, хәтта китабын да күргәнем юк. Дәхи фәлсәфәи диния дигән бер нәрсә сорыйлар. Заһи, беләсеңме, бу нинди гыйлем икән? Зәкиләрдән ишеткәнең юкмы? Шул иске китаплардагы фәлясәфә вә фәлсәфәме[3] икән? Ал әле «Әхтәри», камус! (Алалар — табалмыйлар.) Гөнаһ шомлыклары, бу заманның шәкертләре без исемене белмәгән гыйлемнәрне сорыйлар. Ничек итеп ислахка каршы тормассың? Бер дә тарихе гомуми, җәгърафия, тагын әллә ниләр сорыйлар. Бу нәрсәләрне Зәкиләрдән башка һичкемнән ишеткәнем юк. Җәгърафия дигәнене бер китапта күргән идем дә, ни икәнен аңлый алмадым. Менә күрдең инде шәкертләрнең сораган гыйлемнәрен! Без анларны асла укыта алмаячакмыз. Укыта башласак та, җәһаләтемез мәйданә чыгар да: «Бонлар укыта белмиләр, икенче мөгаллим кирәк», — дип, тагын акыра башларлар. Әллә булмаса, үземез фикъһ, ысуле фикъһ, нәхү, фәраиз вә кәлямнәрне укытып, югарыда әйтелгән гыйлемнәр өчен мөгаллим алдыртыйкмы? Мәхәллә байларына әйтсәк, шөбһәсез, акча җыеп, мөгаллим алдырырлар. Ни дисең бу тугърыда?

Заһи хәлфә (тәмам агарынып, күгәренеп):

— Әмма соң эшнең ахырыны уйламый сөйлисең. Шәкерт сүзенә карап, өстеңә мөгаллим алдырганча дөньядан китү хәерле. Мөгаллим алдырсаң, халык ни сөйләр, Сәли берлән Заһиның шәкертләре: «Сез надансыз — дин дә, фән дә белмисез дип, Сәли вә Заһидан галим мөгаллим алдырганнар», —

---

[1]*Тәшбиһ* — чагыштыру.
[2]*Мәҗаз* — метафора.
[3]*Фәлясәфә вә фәлсәфә* — философлар һәм философия.

дигән агулы сүзләрне ишетүгә ничек түзәрсең? Безнең теләгәнне эшләп, теләмәгәнне ташлап йөргән, нәфсемез[1] белгәнне укытып, белмәгәннәремезне мөгаллимнән укыттыруга ничек разый улыр? Хәзерге шөһрәтләр кайда китәр? Ярый, анлар башка мөгаллим табылганча бездән дә берничә дәрес укырлар, безне билкөлли мәдрәсәдән җибәрмәсләр, бераздан башка мөгаллимнәр табылыр да: «Сез ысуле тәгълим[2] белмисез», фәлән-төгән дип, безне билкөлли мәдрәсәдән үкчә күтәртерләр... Ярый, син мөдәррислекне ташласаң да аптырамассың, — байлыгың бар, ахундлыгың бар, әмма мин кая барырмын? Мин ни берлән дөньямны үткәзермен, ничек тамак туйдырырмын? Син мине бер дә кызганмыйсыңмыни? Үзеңнең шәрикең, вә ничә ел сиңа шәкерт укытып ярдәм иттем. Мине ташламакчымы буласың? Башкача теләсәң ни эшлә, фәкать мөгаллим-фәлән алдырма, — дөньяда минем өчен шунардан кыенлык, шунардан хурлык юк. Ничек итеп: «Менә фәләннәрне без укыта алмыймыз, син укыт», — дип, хурланмыйча, мөгаллимнән укытырга кирәк? Булмас, булмас, мөгаллим алдыртмасмыз!

Заһи белән Сәлинең мөшавәрәсе[3] бик озакка китте. Күп сөйләштеләр вә уйлаштылар. Ахырда һәр икесе ислахның лөзүмен игътираф итсәләр[4] дә, ничек кенә ислах итү дә мәнафигы шәхсияләренә, рәхәт вә сәгадәтләренә хилаф улдыгы өчен һичбер төрле дә ислах итмәскә, ничек булса да шәкертләрне яманлап, ислахның асла кирәк түгеллегене мәхәллә байларына алдап, буяп күрсәтергә карар бирделәр.

Мәхәллә байларына ислахның кирәкмәгәнлеген ничек ышандырырга вә ни рәвешле алдарга — шул хосуста сөйләшеп утыралар иде. Бунларның бәхетенә каршы, мәхәлләнең нөфүзле вә дәүләтле адәмнәреннән дүрт-биш бай килеп керде.

«Әссәламегаләйкем!» — «Вәгаләйкемәссәлам! Хуш килдегез, рәхим итегез!» — дигән сүзләр белән каршыладылар. Байлар утырдылар, сөйләшә башладылар. Иң әүвәл Сәли вә Заһи байларга чиктән тыш тәрилкә тоттылар вә мәгънән сәҗдә иттеләр[5]. Соңра уку-укыту, мәктәп вә мәдрәсә хакында сүз ачтылар. Бу тугрыда сүз бик озын булды. Барыны язачак булсак, укырга ялыгырсыз. Кыскасы гына: хәзрәт вә хәлфәләр мәдрәсәләрдә хәзерге укышны шәригатькә тәмам муафикъ вә бик җиткән һәм һичбер төрле дәрес арттыру, фәлән итү кеби ислахларның кирәге юк; мәдрәсәләрне ислах кирәк дигәннәр, шәкерт булсын, башка булсын, һәммәсе дин ташларга вә бетерергә вә аның

---

[1]*Нәфсемез* — үзебез.
[2]*Ысуле тәгълим* — методика.
[3]*Мөшавәрәсе* – фикер алышуы.
[4]*Игътираф итсәләр* — танысалар.
[5]*Мәгънән сәҗдә иттеләр* — чын мәгънәсендә тез чүктеләр.

урынына кяфер гыйльмене укырга теләүчеләр идекене мең төрле хәйлә, алдау вә буяу илә байларга исбат иттеләр. Монарга каршы байларымыз да: «Хәзрәтләр! Сез йомшаксыз, үзеңез дин башлыгы булып та, динне бетереп, кяфер гыйлеме укырга теләгән шәкертне мәдрәсәдә тотасыз; әгәр дә шулай динне бетереп, кяфер гыйлеме укырга сораучы булса, бер минут тотмый сөреп чыгарыңыз», — җавабыны бирделәр.

Мәҗлес бетте. Байлар да чыгып киттеләр. А! Байлар чыккан соң Сәли берлән Заһи хәлфәдә булган шатлык вә кәефне һич тәгъбир мөмкин түгел. Сәли әйтә:

— Әмма соң мәхәллә байларының наданлыгы вә безем һәр сүземезә ышанучылыклары безем өчен файдалы да. Ислах сораучылар динне бетерергә телиләр дигән идем, гүя ялганлавы мөхаль улан[1] Алланың вәхисе[2] кеби ышандылар. Әгәр дә безгә ышанмаенча: «Тукта әле, без шәкертләрнең ни сорагыныны тикшерик», — дисәләр вә барып тикшерсәләр, ислах сораганны куыңыз дип әйтү кайда, билгакес, анлар: «Диннең асылы улан һәм дә дин үзе важиб иткән[3] гыйлемнәрне сорыйлар икән! Сез ник укытмыйсыз, нигә ислахка карышасыз?» — дип, безне сүгәр иделәр. Ихтимал, ислахка мәҗбүр итәрләр иде. Әле үзләре надан булгач, безгә ышандылар да: «Ислахчыларны куыңыз!» — дип киттеләр. Әмма рәхәт соң!

Заһи:

— Күп шаулама инде, мең төрле ялган берлән булса да байларга ислах кирәкмәгәнлекне бәян иттек, канәгатьләндердек. Шәкертләр гаризаларыны бирә күрмәсен. Ихтимал, сез, хәзрәтләр, безгә ялганлагансыз икән, шәкертләрнең соравы шәригатькә хилаф түгел икән дип, ислах тарафына авыша башларлар. Ул шәкертләр озак тормаслар, имза кылышырлар да байларга бирерләр. Без аңарча Зәкине куып чыгарырга кирәк... Аны чыгарсаңыз, без дә чыгамыз диючеләр булса, һәммәсене дә сөреп чыгару кирәк. Мәдрәсәдә тәфсир, фөнун сүзене моннан соң сөйләтмәскә вә, мондый бозылган адәмнәрдән мәдрәсәне тазартып, укыймы, укымыйммы, теләсә нишләсен, фәкать безә итагать итсен, — шундыйларны гына калдыру кирәк.

Бу хосуста бераз мөзакәрәдән соң[4] Сәли вә Заһи — һәр икесе дә — Зәкине иртәгә мәдрәсәдән куарга, аны химая итүчеләр[5] булса, анларны бергә сөрергә карар бирделәр. Мөзакәрә бетте. Заһи Сәлигә килгәндә ни дәрәҗә кайгылы исә, Сәлидән мәдрәсәгә кайтып киткәндә әүвәлге кайгысы бетеп, соң дәрәҗәдә шатлык илә китте. Мәдрәсәгә кайтканда кич булган иде.

---

[1]*Мөхаль улан* — булуы мөмкин түгел.
[2]*Вәхисе* — берәр фикерне Алла тарафыннан пәйгамбәрнең күңеленә салынуы.
[3]*Важиб иткән* — тиеш күргән.
[4]*Мөзакәрәдән соң* — фикер алышудан соң.
[5] *Химая итүчеләр* – яклаучылар.

Кайтты да бик тыныч йоклады.

Төн үтте. Зәкинең мәдрәсәдән куылачак көне тугды. Һәммә шәкерт, йокыларыннан уянып, чәй эчтеләр. Зәки, бүген төшендә гүя бер зинданга эләгеп, әллә нинди кешеләрдән кыйналып, золым күреп, соңра үзенең котылып чыгуыны күрдекендән: «Ахрысы, байларга гариза бирәчәгемне белеп, мине бу мәдрәсәдән куачаклардыр», — дип уйланып йөрмәктә иде.

Менә бер заман мәдрәсәгә Сәли хәзрәт килеп керде. Сәли, мәдрәсәгә килүе илә бер өлкән бүлмәнең өстәленә утырып, янына Заһи хәлфәне вә Зәки мәхдүмне чакырып алды да һәммә шәкертне җыярга кушты. Шәкертләр җыела: «Ни бар да, ни бар? Гомердә җәмгыять[1] булганы юк иде. Ни эшләп бүген генә җәмгыять ясыйлар?» — тавышлары һәркемнән ишетелмәктә.

Сәли хәзрәт:

— Һәммә шәкертләр җыелдымы?

Шәкертләр:

— Җыелды.

Сәли:

— Шәкертләр җыелган булса яхшы; алайса тавышланмаңыз, менә мин бер кәгазь укыймын, яхшы тыңлаңыз.

Хәзрәт укый. Һәммә шәкерт дүрт колак илә тыңламакта. Бик мөфассал вә озын язылган. Монда хөласасы[2] гына алына. Башына «Итагатьсезлек җәзасы» дип язылган.

«Үзеңезгә мәгълүм, шәкертләрем! Зәки мәхдүм бу мәдрәсәдә ничә еллар укыды вә галим булды. Әүвәлге сәнәләрдә безем иң итагатьле шәкертләремез җөмләсеннән булса да, бу елларда бик бозылды. Итагать итми башлады. «Гыйльмия»[*] мәдрәсәсенең шәкертләренә катышты. Руман вә гәзитә укыды вә шәкертләргә дә алып килеп укытты. Кыйраәтханәгә барды. Әүвәлдә атнасына бер-ике дәрес, хәтта унбиш көнгә бер дәрес бирсәм дә бер сүз димиләр иде.

Шул Зәкинең: «Мантыйк, ихтиляфат вә моназарә берлән гомер уздырырга ярамый, тәфсир, хәдис, фәлсәфәи диния вә фөнун кирәк», — дигән сүзләренә алданып, безгә фәләнчә гыйлемнәр кирәк дип, шәкертләр дә сөйләнә башладылар, безне һәрвакыт хафаладылар. Һәр заман безгә голуме диния вә фөнун укытыңыз дип итагатьсезлек күрсәтә башладылар. Менә Зәки үзенең бозылуы илә генә калмады, шул рәвешле бик күп шәкертләрне дә бозды. Үзенең мәсләгенә кертте вә башка шундый бик күп итагатьсезлекләре

---

[1] *Җәмгыять* — «җыен, җыелыш» мәгънәсендә.

[2] *Хөласасы* — йомгагы.

[*] Язучы “Әльислах” газетасының 1908 нче елның 35 нче санында бер мәртәбә “Фәләния” мәдрәсәсе дип атый.

вә зарарлы хәрәкәтләре булды. Шул кабахәтлекләре өчен Зәкине мәдрәсәдән куарга хөкем иттек».

— Зәки! Ишет син, синең илә арада галяка мөнкатыйг булды[1]. Бер минут торырга рөхсәт юк. Нәрсәләреңне ал да бу сәгать мәдрәсәдән чыгып кит! Моннан соң тәфсир, фәлсәфәи диния, фөнунне агызына алган кешенең берсене дә мәдрәсәдә тотмаячакмыз. Әгәр бу сүзләрне сөйләү фаразында[2] булса, ул кеше дә Зәки белән чыгып китсен!

Әмернамә (тугрысы — золымнамә) укылды. Тәфсир, фөнун сораган өчен Зәки мәхдүм куылырга мәхкүм булды[3].

Зәкинең тарафдарлары:

— Фәхешханә[*] вә пивнойга барган, бар гомерене фәхеш, хәмер артыннан йөреп уздырган шәкертләрне кумыйсыз; тәфсир, фөнун сораудан башка һичбер гөнаһысы булмаган Зәкине ник куасыз? Ничөн урынсыз золым идәсез? — миселле мөдафәгадә[4] булсалар да, файдасы булмады. Истибдад вә тәгассыб җиренә булды[5]. Зәки куылачак булды. Зәкинең иптәшләре аның куылуына наразыйлык[6] күрсәтсәләр дә, безем Зәки мәхдүм үзе һичбер сүз димәде. Ник куасыз дип агыз ачмады. Бу мәдрәсәдән кудылар, фәлән иттеләр дип һич тә агырсынмады. Билгакес: «Бер минут торма, чыгып кит», — сүзләреме ишетеп, гүя зинданнан котылырга әмер булган кеби, йөзендә шатлык әсәрләре күренде. Зәки, һич тә үзгәрми генә, вәкарь вә мәтанәтне мөхафәзә илә[7], мәҗлеснең соңындарак ошбу сүзләрне сөйләде:

— Хәзрәтләр! Фәхеш вә хәмер артыннан йөргәннәрне кумаенча, тәфсир, фән сораган адәмне кууыңыз никадәрле золым вә вәхшәт исә дә, минем бу тугрыда диячәк һич сүзем вә һич шикаятем юк вә сөйләргә хаҗәт тә юк. «Ник куасыз мине?» — дип сөйләр идем, әгәр бу мәдрәсәдән куылуны бер агырлык вә кыенлыкка хисапласам; мин кыенлык хисап итү кайда, билгакес, мондый золым, вәхшәт оясы булган зинданнан котылуым өчен соң дәрәҗә шатланамын. Фөнун, мәгариф өчен сез мөтәгассыблардан куылырлык кадәрле иҗтиһад идә алуымны, сездән куркып, җәһаләткә разый булмавымны үзем өчен бөек кәмаль вә шәрәф саныймын. Фөнун, мәгариф өчен куылганча тырышуымны бөек муаффәкыять дип беләмен, шәрган фарыз вә гаклән лязем улан голүм, мәгариф өчен сезнең золым вә тәгассыбыңыза вә мәдрәсәдән

---

[1] *Галяка мөнкатыйг булды* — бәйләнеш өзелде, киселде.

[2] *Фаразында* — фикерендә, уенда.

[3] *Мәхкүм булды* — хөкем ителде.

[*] Бу сүз "Әльислах"та (1908, №35) – *бардак.*

[4] *Мөдафәгадә* — каршы торуда.

[5] *Истибдад вә тәгассыб җиренә булды* — «деспотизм һәм кирелек, үҗәтлек өстен чыкты» мәгънәсендә.

[6] *Наразыйлык* — ризасызлык.

[7] *Вәкар вә мәтанәтне мөхафәзә илә* — горурлык һәм ныклылык саклап.

кууыңыза илтифат итмәенчә иҗтиһад иттем. Вә моннан соң да бар гомеремне вә бар көчемне, сәгый[1] вә гайрәтемне шул голүм вә мәгариф вә ислахы мәдарис өчен сарыф итәчәкмен. Вә гомум татар шәкертләренең дә голүм, мәгариф вә ислах өчен һичнидән курыкмаенча иҗтиһад итүләрене сорыймын. Тәмам ышанамын ки, моңарча улдыгы кеби, моннан соң да гомум татар мәдрәсәләре ислах ителгәнчә вә шәкертләр бу кадәрле изелүдән сәгадәт галәменә чыкканча һәммә шәкерт көч-куәтене вә иҗтиһадыны шул ислах өчен сарыф итәчәк, вә, һичбер шик юк ки, сез, хәзрәтләр, әллә нинди корал илә карышсаңыз да, ислахның дөньяга чыгуыны туктата алмаячаксыз. Әллә нинди золым вә вәхшәтләр берлән дә шәкертне ислах фикереннән вә хәрәкәтеннән туктата алмаячаксыз. Ислах фикере шәкерткә урнашты вә тамыр җәйде. Халык арасына чәчелмәгә башлады. Фикер орлыгы шундый бер орлык ул, әгәр дә бер җиргә бик аз гына чәчелсә вә урнашса, мотлака[2], бик тиз заманда тамыр җәядер вә бик тиз дөньяга тараладыр. Башка орлыкларның корып, кибеп калуы дөньяга нәбат[3] чыгармый; чыкса да, һәлак булуы ихтимал исә дә, фикер орлыгында бу ихтималлар һич юк. Бу орлыкның дөньядан вөҗүдене[4] бетерүгә никадәрле иҗтиһад ителсә дә, мөмкин булмаячак. Моның хилафына улан һәммә хәрәкәт гакылсызлыктыр. Гакылы бар адәм дөньяга чыккан фикернең бетерелүе өчен иҗтиһад итмәс, чөнки мөмкин түгел; бәлки шул фикернең бераз үзгәрүе, зарарсыз булып мәйданга чыгуы өчен иҗтиһад итәдер. Сез, хәзрәтләр дә, ислахның мәйданга чыкмавы яки мәнафигы шәхсиягә хилаф булмаслык кына ислах идеп, артык ислах ителенмәве өчен никадәрле иҗтиһад итсәңез дә, һәммәсе буш вә гакылсызлыктыр. Ислах бер хакыйкатьтер. Хакыйкать бераз заман кичексә дә, һаман заһир[5] булмый калмаячактыр... Юкны хыял итмәңез, ислахка карышып, мәнафигы шәхсиямезне тәэмин итәмез дип хыялны ташлаңыз; бу юк хыял. Сез әллә ни берлән мөдафәга итсәңез дә, ислах үзен мәйданга куячагында бер дә шөбһә юк. Сезнең карышуыңыз тарих сәхифәсендә бик кара исем алу, голүмвә мәгариф дошманы, җәһаләт вә тәгассыб мөхибе[6], милләт вә инсаният микробы дип исемләнеп, төрле ләгънәтләр илә зикер ителүеңездән[7] башка файда бирмәячәк.

Иштә[8] Зәки шәкерт үзенең куылуына хөкем ителенгән мәҗлеснең соңында гына Сәли хәзрәткә вә Заһи хәлфәгә шул сүзләрне сөйләде.

---

[1]*Сәгый* — тырышлык.
[2]*Мотлака* — шиксез.
[3]*Нәбат* — үсемлек.
[4]*Вөҗүдене* — бар булуны.
[5]*Заһир* — ачык, билгеле.
[6]*Мөхибе* — сөюче.
[7]*Зикер иделүеңездән* — телгә алудан.
[8]*Иштә* — чынында.

Моны сөйләтмәү өчен һәр ике мөдәррис бик тырышсалар да, Зәкинең тарафдарлары: «Сөйләсен дә сөйләсен!» — дип, бик күп кычкырдыкларыннан, Зәки сүзендә дәвам итте. Хәзрәтләр дә, гәрчә каннарына тоз сипкәндәй вә муеннарына пычак салгандай ачулы булса да, агыз-борыннарыны салындырып тыңларга мәҗбүр улдылар.

Шул сүзләр илә мәҗлес тәмам улды. Шәкертләр таралдылар. «Бу минут һәммә нәрсәңне җыйна да мәдрәсәдән чыгып кит!» — сүзләрен әйтеп, Сәли мелла да өенә кайтып китте.

Хәзрәт өенә киткәч, Зәки вә тарафдарлары, бер кечкенә җәмгыять ясап, Зәки ялгызы чыгаргамы, әллә юкса, Зәкине химая идәрәк[1], һәммә тарафдарлары да бергә чыгаргамы? — шул хосуста мөзакәрә иттеләр. Төрле сүзләр сөйләнде. Байтак фикерләр бәян иттеләр. Ахырда шуңа карар бирделәр: «Бу мәдрәсә татарның яхшы вә өлкән мәдрәсәсе. Әгәр дә ислах лөзүмене аңлаган һәммә шәкерт чыкса, калган шәкертләр ислах лөзүмене төшенеп, ислах өчен хәрәкәт башланганчы байтак заманнар үтәр. Мондый күп шәкерт озак замангача золмәт вә җәһаләттә вә Сәлинең истибдадында изелерләр. Әгәр Зәки генә чыгып, башка ислах тарафдарлары һәммәсе калса, аңламаганнарны аңлатып, гомум шәкерт ислахның лөзүмене төшенеп, ихтимал, Сәли мелланы ислахка тәргыйб итәрләр[2] вә бер мәдрәсәнең ислахына сәбәп булырлар», — дип, ялгыз Зәки чыгып, башкалары Сәлинең истибдадыннан шәкертне вә мәдрәсәне котылдыру өчен мәдрәсәдә калуны мөнасиб күрделәр.

Зәки мәхдүм һәммә нәрсәләрене җыйды, мәдрәсәдәге иптәшләре илә эшләрене өзеп, һәммә иптәшләре илә күрешеп, мәдрәсәдән чыгып китте. Вә иптәшләре дә шәкерт садәләре[3] илә озатып, Зәкинең сәгый вә гайрәтләрен вә фидаилеген[4] зикер итәрәк, тәхсин итеп[5] калдылар. Сәли белән Заһи да, халык мәдрәсәсеннән, вәкыйф мәдрәсәдән, тәфсир вә фөнун сораганлыгы өчен берәүне золмән урамга сөреп чыгарарак, җәһаләт вә тәгассыб хамисы[6] улып калдылар.

---

[1]*Химая идәрәк* — яклап.

[2]*Тәргыйб итәрләр* — кызыксындырырлар.

[3]*Садәләре* — җырлары.

[4]*Фидаилеген* — идеал иткән эше өчен үз-үзен аямау, берәр нәрсәгә ирешү өчен үзен кызганмау.

[5]*Тәхсин итеп* — мактап, хуплап.

[6]*Җәһаләт вә тәгассыб хамисы* — наданлык һәм кирелек сакчысы.